... Qazan LENIN isem.
ÖLKƏ MASSA KITAPXANƏSE TƏP KITAP SAQLAV BYLEGE
ОСНОВНОЕ КНИГОХРАНИЛИЩЕ ОБЛАСТНОЙ МАССОВОЙ
им. ЛЕНИНА БИБЛИОТЕКИ АТССР г. Казань

ҖОМГА
8 МАРТ
1940 ел
№ 55 (5855)
*Аерым номеры 10 тиен*

*БАРЛЫК ИЛЛӘРНЕҢ ПРОЛЕТАРИЙЛАРЫ, БЕРЛӘШЕГЕЗ!*

# КЫЗЫЛ ТАТАРСТАН

ВКП(б) Өлкә Комитеты, Шәһәр комитеты, ТАССР Верховный Советы һәм Шәһәр Советы органы.

**РЕДАКЦИЯ АДРЕСЫ:**
*Казан, Матбугат йорты.*
ТЕЛЕФОННАР: экономик бүлек 18—22, авыл хуҗалыгы һәм совет төзелеше бүлекләре 4—58, партия бүлеге һәм матбугат күзәтү бүлеге 14—75, хатлар бүлеге 21—23, культура бүлеге 18—22, информация бүлеге 5—86, төнге редакция 3—75, типография 36—60, бухгалтерия һәм игланнар бүлеге 2—19.

## *Партиянең Казан Шәһәр Комитетының беренче пленумы турында*
## ИНФОРМАЦИОН БЕЛДЕРҮ

7 нче мартта ВКП(б) Шәһәр Комитетының утырышлар залында партиянең Казан Шәһәр Комитетының беренче пленумы булды. Пленум оештыру мәсьәләләрен тикшереп хәл итте.

Пленум, ВКП(б) Шәһәр Комитетының беренче секретаре итеп бер тавыштан иптәш Алемасовны, икенче секретаре итеп иптәш Бычковны, өченче секретаре итеп иптәш Нацибуллинны, кадрлар буенча секретарь итеп иптәш Хәмидуллинны сайлады.

ВКП(б) Шәһәр Комитеты бюросы составына член итеп Алемасов, Бычков, Нацибуллин, Хәмидуллин, Мурин, Тихонов, Ананьев, Гаязеттинов, Новиков иптәшләр, бюро членлыгына кандидатлар итеп Прокофьев, Низаметтинов, Иванов иптәшләр сайландылар.

Пленум, шулай ук, ВКП(б) Шәһәр Комитетының бүлек мөдирләрен раслады. Пропаганда һәм агитация бүлеге мөдире итеп Абдрашитов, кадрлар бүлеге мөдиренең урынбасары итеп Низаметдинов, оештыру - инструкторлык бүлеге мөдире итеп Рыков, хәрби бүлек мөдире итеп Федоров иптәшләр расландылар.

## Бөек илнең бәхетле хатын-кызлары

8 нче Март революцион көрәш тарихында күренекле даталарның берсе. Бу көн — Халыкара Коммунистик Хатын-Кызлар Көне—бөтен дөньядагы хезмәт иясе хатын-кызларның революцион көрәшкә тупланулары көне, империализмга каршы, сугышка каршы көрәшкә тупланулары көне булып тора. Халыкара коммунистик хатын-кызларның сугышчан көчләренә смотр көне булып тора.

Социалистик илнең хезмәт иясе хатын-кызлары 8 нче Март бәйрәмен гаять зур яңа уңышлар белән каршылыйлар. Бөек Социалистик Октябрь революциясенең җиңеп чыгуы нәтиҗәсендә, дөньяда иң беренче буларак азатлыкка чыккан совет хатын-кызлары халык хуҗалыгының барлык тармакларында, дәүләт эшендә, культура төзелешендә ирләр белән бер тигез дәрәҗәдә эшлиләр һәм сокланырлык үрнәкләр күрсәтәләр.

Сталинчыл бишьеллыклар елларында эшче һәм хезмәткәр хатын-кызларның саны аеруча нык үсте. Мәсәлән, 1932 нче елда халык хуҗалыгында 6 миллион 700 мең хатын-кыз эшләгән булса, 1939 нчы елда бу сан 10 миллион 773 мең кешегә җитте.

Илебезнең хатын-кызлары партиянең, хөкүмәтнең һәм бөек Сталинның көндәлек кайгыртучанлык күрсәтүләре белән чолганып алынганнар. Совет хөкүмәте тарафыннан күп балалы аналарга 3 миллиард сумнан артык пособие бирелү— бу кайгыртучанлыкның ачык мисале. Балалар бакчаларының, яслеләрнең һәм площадкаларның киң челтәре, бала тудыру йортлары — болар барсы да совет хатын-кызының горурлыгы, мактанычы булып торалар.

Безнең илебездә хатын-кызлар зур көч. Алар социалистик хезмәтнең гүзәл үрнәкләрен күрсәтүчеләр, яңалыклар кертүчеләр, иҗад итүчеләр. Гризодубова, Раскова, Демченко, Виноградовалар, Ковардак, Паша Ангелина һәм башкаларны безнең илебездә кемнәр генә белмиләр! Совет халкы алар белән урынлы рәвештә мактана. Стахановчылык хәрәкәтенең яңа формаларын — күп станокта эшләү, яңа профессияләрне үзләштерү хәрәкәтен киң җәелдерүдә хатын-кызлар гаять зур активлык, инициатива күрсәтәләр. Моңа орденлы Татарстан республикасы мисаленнән генә дә бик күп фактлар китерергә мөмкин. Җитен комбинаты стахановчысы Галәветдинова берьюлы дүрт станокта, 4 нче номерлы ясалма каучук заводы стахановчыларыннан Ураинская, Большакова, Маркухина иптәшләр берьюлы 30 аппаратта эшләүне үзләштерделәр.

Ленин—Сталин партиясе җитәкчелегендә безнең илебездә колхоз төзелеше җиңде. Меңләгән крестьян хатын-кызларына культуралы тормыш тәэмин ителде. Алар колхоз эшенең барлык тармакларында һәм колхозның җитәкче органнарында актив эш алып баралар. Колхозчы хатын-кызлардан катлаулы техниканы үзләштергән бик күп кадрлар үсеп чыктылар. „Хәзер инде ул кыз чагында—атасына, иргә чыккач—иренә эшләми, ә барыннан да элек үзенә эшли. Менә бу инде крестьян хатын-кызын азат итү дигән сүз, бу инде хезмәт иясе хатын-кызны һәрбер хезмәт иясе ир белән тигез итүче колхоз строе дигән сүз“ **(Сталин).**

Совет хатын-кызына Сталин Конституциясе нигезендә хуҗалык, дәүләт, культура һәм иҗтимагый - политик тормышның барлык өлкәләрендә дә ирләр белән бер тигез хокуклар бирелде. Совет халкы илебезнең иң алдынгы хатын-кызларын, Ленин—Сталин партиясе эшенә чын күңелдән бирелгән хатын-кызларны СССР, союзный һәм автономияле республикаларның Верховный Советларына сайлап, аларга гаять зур ышаныч күрсәтте. СССР Верховный Советында хатын-кызлардан 189 депутат, Союзный һәм автономияле республикаларның Верховный Советларында 1 мең 436 депутат, хезмәт ияләре депутатларының җирле Советларында хатын-кызлардан 422 мең 179 депутат дәүләт өчен, халык өчен гаять әһәмиятле эшләр башкаралар. Бу, Сталин Конституциясенең тормышка ашырылуының ачык чагылышы.

Капиталистик илләрдә хезмәт иясе хатын-кызлар рәхимсез рәвештә эксплоатацияләнәләр. Алар капиталистик производствода иң авыр шартларда эшлиләр. Ирләр белән бер үк шартларда эшләсәләр дә, аларга хезмәт хакы ким түләнә. Мәсәлән, Англиядә бер үк төрле эш өчен хатын-кызларга ирләргә караганда 60 процент ким түләнә. Англия һәм Франция империалистлары тарафыннан Европада башланган һәм көннән-көн коточкыч төс ала барган сугыш хезмәт иясе хатын-кызларның хәлен тагын да авырайтты. Капиталистик илләрнең хезмәт иясе хатын-кызлары 8 нче Март көнендә, Коммунистик Интернационал байрагы астына баскан хәлдә, үзләренең азатлыклары өчен, сугыш богауларын өзеп ташлау өчен, эксплоататорларга каршы көрәшкә тупланалар.

Социалистик илнең хатын-кызлары—совет патриотлары илебезне саклауда актив катнашалар. Хасан күле буенда, Халхин-Гол елгасы янында япон самурайларын тар-мар иткәндә, Көнбатыш Украина, Көнбатыш Белоруссия халыкларын Польша паннары тырнагыннан азат иткәндә совет хатын-кызлары Кызыл Армиягә якыннан торып ярдәм иттеләр. Хәзер ак финнәргә каршы Кызыл Армиянең героик көрәшендә дә алар актив катнашалар. Ватаныбызны саклауда геройлык күрсәткән өчен Ленин ордены белән бүләкләнгән хәрби фельдшер В. И. Титкова, „Кызыл Йолдыз“ ордены белән бүләкләнгән хәрби врач Иоффе иптәшләр һәм башкалар белән без бик урынлы мактанабыз һәм горурланабыз.

Яшәсен 8 нче Март—Халыкара Коммунистик Хатын-Кызлар Көне!

Яшәсен бөек Сталин!

### ВКП(б) ның Татарстан өлкә оешмасының XXI нче конференциясе делегатлары игтибарына

Партиянең Татарстан өлкә оешмасының XXI нче конференциясе шушы елның 10 нчы мартында, 18 сәгаттә, Менжинский исемендәге клубта ачыла. (Казан, Карл Маркс урамы, 26).

Делегатларны теркәү һәм делегатлык билетлары бирү 8 һәм 9 нчы мартта 9 сәгаттән 23 сәгаткә кадәр һәм 10 нчы мартта 9 сәгаттән 16 сәгаткә кадәр, ВКП(б) ның Татарстан Өлкә Комитеты бинасында, 35 нче бүлмәдә булачак (Казан, Б. Красный урам, 38). Оештыру комиссиясенең телефоннары: 26—80, 13—30, яки Өлкә Комитеты коммутаторы аркылы—10.

*Оештыру комиссиясе.*

Сталин район советы депутаты, 4 нче мех фабрикасының алдынгы стахановчысы Язилә иптәш Гатауллина. Ул шушы елның башында кисү цехының участкы мастеры булып күтәрелде. М. Солтанов фотосы.

## ПАРТИЯНЕҢ КАЗАН ШӘҺӘР КОНФЕРЕНЦИЯСЕ

Конференциянең 6 нчы мартта-гы утырышларында ВКП(б) Шәһәр Комитеты пленумы составына членлыкка һәм кандидатлыкка кандидатуралар күрсәтү, ревизия комиссиясенә членлыкка һәм партиянең Татарстан оешмасының XXI нче Өлкә конференциясенә делегатлыкка кандидатуралар күрсәтү, аларны тикшерү һәм сайлаулар булды. Ябык (яшерен) сайлаулар нигезендә ВКП(б) Шәһәр Комитеты пленумы составына член итеп 57 кеше, кандидат итеп 11 кеше, ревизия комиссиясенә 9 кеше сайланды. Партиянең Татарстан оешмасының XXI нче Өлкә конференциясенә тавыш бирү хокукы белән 145 делегат, киңәш бирү хокукы белән 31 делегат сайланды.

Конференция бөек юлбашчыбыз иптәш **Сталинга** һәм Совет хөкүмәте башлыгы иптәш **Молотовка** хат кабул итте. Делегатлар иптәш Сталин исменурыннарыннан торып хөрмәтләделәр. **„Яшәсен бөек юлбашчыбыз һәм өйрәтүчебез даһи Сталин!“** дигән тавышлар яңгырап торды. Конференция, шулай ук, Ленинград Хәрби Округының героик сугышчыларына, командирларына һәм политработникларына котлау хаты җибәрде.

### ПАРТИЯНЕҢ V нче КАЗАН КОНФЕРЕНЦИЯСЕ ТАРАФЫННАН ВКП(б) ШӘҺӘР КОМИТЕТЫ ПЛЕНУМЫ ЧЛЕННАРЫ ИТЕП ТҮБӘНДӘГЕ ИПТӘШЛӘР САЙЛАНДЫЛАР:

1. Абдулманов З. З.
2. Алексеева А. А.
3. Алемасов А. М.
4. Ананьев Ф. Т.
5. Арнаутов А. Д.
6. Әхметшина Р. С.
7. Булатов Х. П.
8. Бычков И. Г.
9. Варламов В. В.
10. Васильев В. И.
11. Гафиятуллин С. Х.
12. Гаязеттинов А. Г.
13. ДинмөхәметовГ. А.
14. Долотказин А. У.
15. Ерин И. И.
16. Жуков К. П.
17. Зәйнуллина М. Ш.
18. Закиров З. С.
19. Захаров В. И.
20. Иванов А. Г.
21. Измайлова Г. К.
22. Иоффе К. И.
23. Колесников Ф. И.
24. Кудрявцев Л. Н.
25. Лебедев А. В.
26. Мальков М. И.
27. Матвеев Е. Я.
28. Матвеев П. А.
29. Мельников А. М.
30. Мифтахуттинова С. М.
31. Морозов Е. М.
32. Мурин Г. И.
33. Мөхәметов С. А.
34. Насибуллин С. Н.
35. Нацибуллин Я.
36. Низамутдинов Ш. Н.
37. Никитин И. Ф.
38. Новиков М. М.
39. Орлов П. М.
40. Перов А. П.
41. Прокофьев С. Е.
42. Рыков А. И.
43. Рябинин К. А.
44. Сафин Г. С.
45. Соколов А. С.
46. Суриков И. Ф.
47. Таҗиева Г. Т.
48. Тарасов И. Г.
49. Тихонов Г. П.
50. Тышкевич Д. М.
51. Фәхреттинова А. К.
52. Филиппов С. А.
53. Хәмидуллин Р. Г.
54. Шипов В. З.
55. Штейнберг И. И.
56. Шепетова Ф. Е.
57. Якимов М. Н.

### ВКП(б) ШӘҺӘР КОМИТЕТЫ ПЛЕНУМЫ ЧЛЕНЛЫГЫНА КАНДИДАТЛАР ИТЕП ТҮБӘНДӘГЕ ИПТӘШЛӘР САЙЛАНДЫЛАР:

1. Абдрашитов И. И.
2. Андреев П. А.
3. Бикбов А. Х.
4. Маркин Г. П.
5. Орехов П. Н.
6. Сафонов В. П.
7. Соколова П. М.
8. Степанов И. Х.
9. Уразов К. Т.
10. Шпаков И. М.
11. Ястребилов Е. Т.

### ВКП(б) ШӘҺӘР КОМИТЕТЫНЫҢ РЕВИЗИЯ КОМИССИЯСЕ ЧЛЕННАРЫ ИТЕП ТҮБӘНДӘГЕ ИПТӘШЛӘР САЙЛАНДЫЛАР:

1. Аксенов М. Л.
2. Бисеров А. М.
3. Елисеева О. И.
4. Кузнецов Н. А.
5. Назаров П. С.
6. Семенов П. П.
7. Ситников К. П.
8. Шәихов Б. Б.
9. Шохов И. С.

## ЛЕНИНГРАД ХӘРБИ ОКРУГЫ ШТАБЫНЫҢ ОПЕРАТИВ СВОДКАСЫ

5 нче мартта Карелия бугазында Выборг заливы районында безнең частьләр **Раван-Саари** атавын һәм **Раван-Саари** шәһәрен, шулай ук **Суонион-Саари** атавын алдылар. **Выборгдан** төньяк-көнчыгышта **Выборг-Сердоболь** тимер юлындагы **Карисалми** станциясеннән бер километр көнчыгышта **Неетеля** местечкосы алынды.

Фронтның башка участкыларында әһәмиятле бер нәрсә дә булмады.

Безнең авиация дошманның гаскәрләренә һәм сугыш объектларына актив хәрәкәтләр алып барды. Һавада булган сугышларда дошманның 21 самолеты бәреп төшерелде.

***

6 нчы мартта фронтта әһәмиятле бер нәрсә дә булмады.

Безнең авиация дошманның гаскәрләренә һәм сугыш объектларына актив хәрәкәтләр алып барды. Һавада булган сугышларда дошманның 3 самолеты бәреп төшерелде.

## Чит илләрдә

### *Финляндиядә Кызыл Армиянең уңышлары турында Германия матбугаты*

БЕРЛИН, 5 март. (ТАСС). Германия газеталары Кызыл Армиянең ак финнәргә каршы операцияләре турында хәбәрләр басуны дәвам иттерәләр. „Националь цейтунг“ газетасының Хельсинкидәге хәбәрчесе, Выборг тирәсендә булган зур сугышлар турында хәбәр итеп, Совет гаскәрләренең куәтле һөҗүменә финнәрнең каршылык күрсәтә алмаганлыклары турында яза. Хәбәрче болай дип яза: „Финнәр Маннергейм линиясендәге позицияләрдән чигенделәр һәм яңа ныгытмаларга күчәргә мәҗбүр булдылар. Совет гаскәрләре финнәрнең оборона корылмаларын өзделәр. Финнәрнең хәрби сводкаларында, зур җиңелүләр турында дәшмәүне дәвам иттерсәләр дә, фин гаскәрләренең чигенүен инде икрар итәләр“. Хәбәрче Выборг районында фин частьләренең гаять зур югалтуларга дучар булуларын һәм Совет гаскәрләренең батырлыгын һәм кыюлыгын күрсәтеп үтә. Хәбәрче, Совет частьләренең берсе финнәрнең зур берләшмәсенең чигенү юлын кисә алды һәм финнәрне Выборгдан көнчыгыштарак урманга куып кертә алды дип яза.

„Варшауер цейтунг“ газетасының Копенһагендагы хәбәрчесе Кызыл Армиянең Финляндиядәге уңышларына Даниядә зур игтибар бирәләр дип яза. Копенһагенда чыга торган „Политикен“ газетасы Хельсинкидән алынган хәбәрендә Совет частьләренең һөҗүме көчәйгәннән-көчәя бара дип яза.

### *Кызыл Армиянең ак финнәрне җиңүе турында Болгария матбугаты*

СОФИЯ, 6 март. (ТАСС). Финляндиядәге сугыш хәрәкәтләрен аңлатып, „Заря“ газетасы фин подразделениеләренең Кызыл Армия частьләренә кушылулары вакыйгаләре ешайды дип яза.

Газета: „Сугыш күзәтүчеләренең бәя бирүләренә караганда, Маннергейм гаскәрләре таркаулык һәм төшенкелек хәлендә“ дип яза.

Иртәнге газеталар ак финнәр „хөкүмәтенең“ Милләтләр Лигасына җибәргән „нота“ дигән нәрсәсен Ленинград Хәрби Округы Штабының ялганга чыгаруын иглан итәләр. „Заря“ газетасы газлар куллануны Кызыл Армиянең моральгә каршы җинаять һәм гомуми рәвештә гаепләнергә тиешле нәрсә дип санавын аеруча күрсәтеп үтә. Шуның белән бергә газета совет авиациясенең тыныч халыкны бомбага тотмавын һәм совет частьләре тарафыннан Маннергейм линиясенең иң әһәмиятле пунктлары өзелгәнлекне күрсәтә.

„Борьба“ газетасы, Англияне һәм Францияне күздә тотып, болай дип яза: „Бөтен дөнья сугышыннан соң иске политик „гөнаһлылар“ бөтен дөнья күләмендә үзләренең өстенлекләрен һәм эгоистик материаль интересларын ныгытырга һәм кечкенә дәүләтләрне үз якларына тартырга омтылып, аларга искиткеч җиңеллек белән дошманның территория кисәкләрен һәм колонияләрен өләштеләр.

Шушы „гөнаһлыларның“ бөтен дөнья күләмендә өстенлеген яклау өчен кайбер кечкенә дәүләтләр бик нык коралландылар. Мәкерле „рәхимлеләр“нең акча сандыклары һәм сугыш заводлары алар өчен киң итеп ачылды. Алар төшләрендә еракка ата торган орудиеләр, тиз ата торган пулеметлар, танклар, аеропланнар, су асты көмәләре, крейсерлар, агулый торган газлар һәм башка нәрсәләр күрделәр“. „Боларның барсын да беренче чиратта Финляндиягә кайтарып калдырырга мөмкин. Аның кирелеге һәм акылсыз каршылык күрсәтүе аны коралландырган „рәхимлеләр“ өчен бик файдалы“.

### Англия һәм Франция авиациясенең югалтулары

БЕРЛИН, 5 март. (ТАСС). „Фелькишер беобахтер“ газетасы „Германиянең көче, Британиянең ялганы“ дигән мәкаләдә болай дип яза: „Сугышның беренче алты ае эчендә көнбатыш державаларның 335 самолетларын югалтулары турында, ә Германиянең бары тик 78 генә самолетын югалтуы турында немецләрнең раслаулары белән көнбатыш державалар, билгеле, килешмәячәкләр. Лондонга һәм Парижга бу фактны икрар итү кыен, чөнки анда һәр вакыт үзләренең һава флотларының өстенлеген исбат итәргә тырышалар. Британия самолетларының Берлин өстендә очулары турында көнбатыш державалар күптәннән үк хәбәр итәләр инде. Ләкин Англия самолетын Берлиндәге 4 миллион халыктан берәүнең дә күрмәве һәм ишетмәве гаҗәп. Күрәсең, без барыбыз да чукракланганбыз һәм сукырайганбыз ахрысы. Без бу ялган хәбәрләрнең сугыш алып баруда уңышсызлык нәтиҗәсе икәнлеген беләбез. Англия уңышлар яулап аласы урында аларны уйлап чыгара. Бу балаларча уйларның бәясен киләчәк күрсәтер“.

### Германия күмерен Италиягә кертү турында Италия белән Англия арасында вакытлы килешү

РИМ, 5 март. (ТАСС). Барлык газеталар кичә үзләренең беренче битләрендә Англиягә Италиянең протест нотасын зур хәрефләр белән басып чыгардылар. Шул ук вакытта Роттердамнан алынган телеграмма да иглан ителде. Бу телеграммада Италия хөкүмәте белән Англия хөкүмәте арасында ике айлык срок белән килешү төзелгәнлек һәм шушы срок эчендә Германиядән Италиягә яңадан күмер кертеләчәк турында хәбәр ителә. „Трибуна“ газетасы 5 нче мартта, Англиянең ташламаларыннан канәгатләнү белдереп, „Безнең артык китмәячәк чигебезне англичаннарга бөтен ачыклыгы белән әйтергә һәм күрсәтергә вакыт җитте“ дип яза. „Популо ди рома“ газетасы 4 нче мартта болай дип яза: „Англия диңгездә сугышуның халыкара законнарын үтәргә тиеш, ә ул аны сугышмаучы илләргә карата бик еш һәм гадәттән тыш җиңеллек белән бозып килде“.

### КЫТАЙ-СОВЕТ КУЛЬТУРА ЭЛЕМТӘСЕ ҖӘМГЫЯТЕНЕҢ ҖЫЕЛЫШЫ

ЧУНЦИН, 5 март. (ТАСС). 3 нче мартта Чунцинда СССР белән Кытай арасында культура элемтәсе җәмгыятенең төзелүенә бер ел тулуга багышланган җыелышы булды. Җыелышта җәмгыятнең председателе — Кытайның закон нар чыгару палатасы председателе доктор Сунь Фо, председатель урынбасарлары — Гоминданның карт члены Шао Ли-цзы һәм Кытайның мәгариф эшләре министре Чень Ли-фу, җәмгыятнең актив работникларыннан 250 дән артык кеше, Кытай матбугаты һәм СССР илчелеге вәкилләре һәм башкалар катнаштылар. Җыелышта шулай ук Гоминданның пропаганда бүлеге мөдире доктор Ван Ши-цзе һәм рус әдәбияты профессоры Чжан Си-ман катнаштылар. Сунь-Фо речь сөйләде. Җәмгыят председателенең урынбасары Шао Ли-цзы җәмгыятнең эше турында отчет ясады.

Җыелышта доктор Ван Ши-цзы һәм СССР ның Кытайдагы илчесе иптәш А. С. Панюшкин да речь сөйләделәр.

### ХРОНИКА

ССР Союзы Совнаркомы иптәш **Н. Е. Чесноковны** СССР текстиль промышленносте халык комиссарының урынбасары итеп билгеләде һәм аны СССР Текстиль Промышленносте Халык Комиссариаты коллегиясе составына кертте.

ССР Союзы Совнаркомы СССР ның Сәламәтлек Саклау Халык Комиссариаты коллегиясен халык комиссары иптәш **Г. А. Митерев** председательлегендә һәм **С. А. Колесников** (нарком урынбасары), **С. И. Миловидов** (нарком урынбасары), **А. Г. Терентьев** (нарком урынбасары), **Т. Я. Ткачев, И. И. Рогозин, А. Б. Александровский, А. Н. Шабанов** һәм **А. Ф. Третьяков** (РСФСР Сәламәтлек Саклау наркомы) иптәшләр составында раслады.

# ПАРТИЯ ТОРМЫШЫ

## Партиянең район конференцияләрендә һәм җыелышларында

Калинин районының партконференциясе 3 көн дәвам итте. Райком секретаренең отчет доклады буенча 31 делегат чыгыш ясады. Райком составына 21 член, 7 кандидат сайланды.

Беренче пленум иптәш Вәлиуллинны райкомның беренче секретаре итеп, иптәш Сәлимовны икенче секретарь, иптәш Садыртиновны кадрлар буенча секретарь итеп сайлады.

Партиянең **Чүпрәле** район конференциясе эшенә тавыш бирү хокукы белән 71, киңәш бирү хокукы белән 23 кеше катнашты. Райком секретаре иптәш Басыйровның отчет доклады буенча 39 делегат чыгыш ясады. Конференция райкомның эшен канәгатьләнерлек дип тапты. 23 членнан һәм 6 кандидаттан райкомның яңа составы сайланды.

Райкомның беренче пленумы Басыйров, Рәхмәтуллин һәм Андреев иптәшләрне райком секретарьлары итеп сайлады.

Әлмәт районының партконференциясе тәмам булды. Яңа райкомның пленум составына 27 член, 7 кандидат сайланды.

Пленумның беренче утырышы булды. Биков, Фазлиев һәм Саттаров иптәшләр райком секретарьлары итеп сайландылар, райкомның бүлек мөдирләре расландылар.

Партиянең **Ворошилов** район конференциясенә 91 делегат катнашты. Секретарь иптәш Сәмигуллин ВКП(б) райкомының эше турында отчет ясады. Аның доклады буенча 30 кеше чыгып сөйләде.

Конференция райкомның эшен канәгатьләнерлек дип тапты. 19 членнан һәм 5 кандидаттан райком пленумының яңа составы сайланды.

Райкомның беренче пленумы 7 кешедән бюро төзеде, Сәмигуллин, Рәшитов һәм Хәйруллин иптәшләрне райком секретарьлары итеп сайлады.

Партиянең **Азнакай** район конференциясендә райком секретаре иптәш Хәмидуллин отчет докладын ясады. Отчет чоры эчендә оешма 113 процентка үсте. 16 яңа башлангыч партоешма төзелде. Коммунистлардан һәм партиясезләрдән 156 кеше җитәкче эшләргә күтәрелде.

Отчет доклады буенча 37 кеше чыгып сөйләде. Конференция райкомның эшен канәгатьләнерлек дип тапты.

**Бөгелмә** районының 8 нче партконференциясе үзенең эшен тәмамлады. Делегатлар райкомның эше турындагы отчет докладын зур активлык белән тикшерделәр. Доклад буенча 45 кеше чыгып сөйләде.

31 членнан һәм 9 кандидаттан райкомның яңа составы сайланды.

3 нче мартта беренче пленум булды. Ул 7 членнан райком бюросын сайлады.

Партиянең **Буа** район конференциясе зур активлык белән үтте. Конференциядә тавыш бирү хокукы белән 80 һәм киңәш бирү хокукы белән 19 делегат катнашты. ВКП(б) райкомы секретаре Әхтәмов һәм ревизия комиссиясе председателе Юсупов иптәшләрнең отчет докладлары тыңланды.

ВКП(б) райкомының отчет доклады буенча 34 кеше чыгып сөйләде. Чыгыш ясаган иптәшләр райкомның һәм аның бүлекләренең эшләрен, бигрәк тә оештыру - инструкторлык бүлегенең эшен кискен рәвештә тәнкыйтьләделәр.

Конференция ВКП(б) райкомының эшен канәгатьләнерлек дип тапты.

Райком пленумының беренче утырышы ВКП(б) райкомының беренче секретаре итеп иптәш Әхтәмовны сайлады.

Алабуга районының партконференциясе үзенең эшен тәмамлады. Яшрен тавыш бирү тәртибендә 35 кешедән ВКП(б) райкомының яңа составы сайланды, ревкомиссия членнары һәм өлкә конференциясенә делегатлар сайланды.

Райкомның пленумы булды. Беренче секретарь итеп Петров, икенче секретарь итеп Сидоров, кадрлар буенча секретарь итеп Костин иптәшләр сайландылар.

(ТатТАСС).

Баулы районының партконференциясе өч көн дәвам итте.

Отчет доклады буенча фикер алышуларда 37 делегат чыгып сөйләде. Конференция 25 член һәм 7 кандидат составында пленум сайлады. Алар арасында 5 хатын-кыз.

Пленум райкомның беренче секретаре итеп иптәш Шәрәфетдиновны һәм икенче секретаре итеп иптәш Куманцевны сайлады.

## ДИНГӘ КАРШЫ ПРОПАГАНДА ЭШЕН КӨЧӘЙТИК

Хезмәт ияләре депутатларының җирле Советларына сайлаулар вактында Кайбыч районының Зур Подберезье һәм Зур Урсак авылларында дингә каршы пропаганда эше киң җәелдерелде. Бу авылларда укытучылар көче белән колхозчылар өчен фәнни популяр темаларда лекцияләр һәм докладлар үткәрелде. Зур Подберезье укытучылары Захаров һәм Петров иптәшләр 25 беседа-доклад үткәрделәр. Зур Урсак авылының тулы булмаган урта мәктәп укытучысы иптәш Гарифуллин дингә каршы пропаганда буенча күп кенә лекцияләр һәм докладлар укыды. Колхоз клубында дингә каршы темада 2 тапкыр спектакль куелды.

ВЛКСМ Өлкә Комитеты лекторы иптәш Горбунов дингә каршы темада районда 9 лекция укыды. Колхозчылар аның лекцияләрен яратып тыңладылар һәм киләчәктә дә мондый лекцияләрне ешрак оештыруны сорадылар.

Ләкин районның барлык авылларында да дингә каршы пропаганданың куелышы канәгатьләнерлек түгел әле. Сугышчан Алласызлар Союзы район Советының (председателе иптәш Кәримов) бу эшкә җитәкчелеге йомшак. 11 айдан бирле район советының пленумы да үткәрелмәгән. Сугышчан Алласызлар Союзының кайбер авыллардагы башлангыч оешмалары бөтенләй таркалу хәленә килеп җиткәннәр. Район советы районда хәтта ничә башлангыч оешма барлыгын да белми.

Дингә каршы пропаганда эше йомшак куелган урыннарда, мәсәлән, Кече Подберезье, Иске Тәрбит һәм Бакырчы авылларында дини гореф-гадәтләрне үтәү фактлары шактый киң урын алган. Мәктәпләрдә һәм ата-аналар арасында дингә каршы пропаганда эше оештырылмаган. РОНО һәм аның методик кабинеты бу мәсьәләгә игтибар бирмәгәннәр.

*Н. Морозов.*

Калинин районында дингә каршы пропаганда эше тиешле югарылыкка куелмаган. Хезмәт ияләре өчен популяр лекцияләр һәм докладлар үткәрелми. Бу өлкәдә Сугышчан Алласызлар Союзының район советы һәм аның башлангыч оешмалары йомшак эшлиләр. ВКП(б) райкомының пропаганда һәм агитация бүлеге мөдире иптәш Сираҗиев бу эшне яхшырту белән кызыксынмый. Районда чыга торган „Сталин юлыннан“ газетасы (редакторы иптәш Ханипов) дингә каршы пропаганда эшенең куелышы турындагы мәсьәләләрне җитәрлек яктыртмый.

*А. Агафонов.*

## Партинформаторлар яхшы эшлиләр

Әлмәт районындагы башлангыч партоешмаларның күпчелеге партҗыелыш протоколларын райкомга үз вактында җибәрә, ә райкомның инструкторлары аларны укып һәм тикшереп торалар. Инструкторлар, протоколларны тикшергәндә партҗыелышларның план буенча үткәрелүенә, протоколларның дөрес төзелүенә, карарларның дөрес булуына һәм партия демократиясе мәсьәләләренә аеруча нык игтибар бирәләр. Протоколларны шулай тикшереп бару, партоешмалардагы кимчелекләрне вактында ачуга һәм ул кимчелекләрне бетерүгә зур ярдәм итә. Мәсәлән, протоколларны тикшерү нәтиҗәсендә, Югары Мактама авылында комсомол оешмасына кандидатлар группасының җитәкчелек итмәве беленде. Бу факт райком бюросына куелды һәм тиешле чара күрелде.

Шулай ук партинформаторлар партоешмалардагы кимчелекләрне бетерүдә райкомга зур булышлык күрсәтәләр. Башлангыч партоешмаларда 42 коммунист партинформатор итеп сайлап алынды. Алар башлангыч оешмаларның эшләрендәге уңышлар һәм кимчелекләр турында райкомга системалы рәвештә сигналлар биреп торалар. Мәсәлән, иптәш Фролов „Яңа Тормыш“ колхозы янындагы башлангыч партоешма секретаре иптәш Нәҗмиевнең эчүчелек белән шөгыльләнүе турында сигнал биргән иде. Тикшерү нәтиҗәсендә, бу факт расланды. Райком бюросы иптәш Нәҗмиевкә карата конкрет чара күрде.

Иптәш Хәсәнев Югары Мактама авыл Советында зурларны укыту эшенең начар торуы, тулы булмаган урта мәктәптә йөрешнең түбән булуы турында сигналлар биргән иде. Райком, иптәш Хәсәнев сигналлары буенча тикшерү оештырды һәм ул кимчелекләрне бетерү буенча конкрет чаралар күрде.

*Ф. Шаляпин.*

**2 нче номерлы тегү фабрикасының яш стахановчыларыннан (сулдан унга) Гайшә Нурмөхәмитова, Нәгыймә Якупова һәм Раиса Юдина иптәшләр. Алар комсомол оешмасы тарафыннан ВЛКСМ членыитеп кабул ителделәр.** Л. Попов фотосы (ТатТАСС фотохроникасы).

ЯЗГЫ ЧӘЧҮГӘ ХӘЗЕРЛЕК

## САРМАН РАЙОНЫНЫҢ ЧӘЧҮГӘ ХӘЗЕРЛЕГЕ

(Телефон буенча)

Сарман районы колхозларында язгы чәчүгә хәзерлек эше соңгы көннәрдә шактый алга китте. Җитен һәм киндер орлыгыннан тыш, районның чәчүлек орлыклары үзенә җитәрлек. Колхозлар җитен һәм киндер орлыкларын башка районнардагы колхозлардан алмашып алу чарасына керешәләр.

Авыл хуҗалыгы инвентарьларына ремонт ясау тәгәлләнеп килә. Колхозлардагы 1.400 данә сабанның 1.250 данәсе ремонттан чыкты. 2.043 тимер тырма һәм 531 культиватор тулысынча ремонтланды. 270 чәчкеченең 30 данәсенә генә ремонт ясыйсы калды. Ремонтның сыйфаты канәгатьләнерлек.

„Кызыл Ләке“, „Кызыл Буразна“, „Кызыл Пробуждение“, „Кызыл Дружба“ колхозлары язгы чәчүгә хәзерлектә алдынгы сафта баралар. Бу колхозларда кышкы агротехника чаралары яхшы үткәрелә, чәчү орлыклары тулысынча чистартылды. Ефремовчы звенолар чәчүгә хәзерлектә зур активлык белән эшлиләр.

Колхозларда бөртекле культуралар чәчүне планлаштыру эше партия һәм хөкүмәт карарында күрсәтелгән тәртиптә алып барылды һәм бу җаваплы эш үз вактында тәмам булды. Бөртекле культуралар чәчүне планлаштыру эшенә колхозчылар зур активлык белән катнаштылар. Алар бик күп кыйммәтле тәкдимнәр керттеләр. Яңача планлаштыру нәтиҗәсендә районда бодай һәм солы чәчү мәйданы бер кадәр артты.

Хәзер барлык көчне чәчүгә хәзерлек эшен яхшы итеп тәгәлләүгә туплыйбыз.

*Мусин.*

Район җир бүлегенең баш агрономы.

## Гектардан 100 пот уңыш алу өчен

Кайбыч районының „Кече Кайбыч“ колхозы членнары бөртекле культураларның һәр гектарыннан кимендә 100 пот иген уңышы алуга ирешү өчен „Беренче Май“ колхозы членнарын социалистик ярышка чакырганнар иде.

„Кече Кайбыч“ колхозы членнары бу йөкләмәне үтәү өчен нык көрәш алып баралар. Колхозда язгы чәчүгә хәзерлек көннән-көн кызуырак темп ала бара. Чәчү орлыкларын триерлау тәгәлләнде. Алар яхшы һәм коры урыннарда саклана лар. Орлыкларның саклынышы системалы рәвештә тикшерелеп барыла. Авыл хуҗалыгы машиналары һәм транспорт инвентарьлары да тулысынча хәзер. Кар тоту һәм җирле ашламалардан кош тизәге хәзерләү планнары арттырып үтәлде. Көл җыю планы да үтәлеп килә инде. Басуга тирес чыгару буенча еллык план 70 процентка үтәлде.

Агротехниканы өйрәнү түгәрәге тәртипле рәвештә эшли. Аңар колхозның агротехнигы иптәш Тимершин җитәкчелек итә. Түгәрәктә хәзергә кадәр 13 занятие булды инде. Анда һәр вакыт 30—40 колхозчы катнаша.

Бригадалар арасында да социалистик ярыш договорлары төзелгән. Ярыш договорларының үтәлешен тикшерүгә нык игтибар бирелә. Соңгы тапкыр тикшерүдә агрономия чараларын үтәү буенча беренче бригаданың (бригадиры иптәш Шәмсеттинев) алда баруы беленде. Ул планнарны арттырып үтәгән.

Язгы чәчүгә хәзерлектә колхозчылардан Х. Курмаева, Х. Газизова, В. Кадыйров һәм Ш. Солтанов иптәшләр бигрәк тә яхшы катнашалар.

*Г. Гобәев.*

## Атлар турында онытканнар

Әлмәт районының кайбер колхозларында атларны язгы чәчүгә хәзерләү эше бик начар тора. Мәсәлән, „Дирижабль“ колхозының 3 нче бригадасында 11 ат түбән көрлектә. Ләкин бу атларны аерым тәрбиягә кую турында уйлап та караучы юк. Колхоз җитәкчеләре (правление председателе иптәш Мөхәммәдиев) „вакыт бар әле, өлгерербез“ дигән зарарлы настроениегә бирелеп, үзләрен тынычландыралар.

„Зәй“ колхозы җитәкчеләренә карата да шуны ук әйтергә кирәк. Монда да түбән көрлектәге атлар әле һаман аерым тәрбиягә һәм ялга куелмаганнар. Колхозда терлек азыгы җитмәү куркынычы бар, ә колхоз правлениесе азык хәзерләү турында кайгыртмый. Эчке мөмкинлекләрдән файдалануны оештырмый, дәүләттән ссуда көтеп ята.

Районда фураж фондлары үзләреннән арткан колхозлар бар. Ләкин район җир бүлеге колхозлар арасында фураж белән үзара ярдәмләшүне оештырмый.

*З. Салахетдинов.*

## Арба һәм чана турында

Хуҗалык бурычларын уңышлы үтәү өчен көрәштә колхоз транспорт инвентаренең җитәрлек һәм төзек булуы бик әһәмиятле.

Кызганычка каршы, Алабуга районының күп кенә колхозларында транспорт инвентаре һәм сбруйлар эш атлары санына карата һич тә җитәрлек түгел. Конкрет фактларга күчик: „Туйма“ колхозында 46 атка бары 23 арба, 29 чана һәм 31 камыт бар. „Красный луч“ колхозында 39 атка 16 арба, 19 чана, „Вторая пятилетка“ колхозында 90 атка 43 арба, 45 чана бар.

Районда колхозлар өчен транспорт инвентаре хәзерләү эше Леспромхозның „Смычка“ артеленә генә тапшырылган. Бу артель колхозларның соравын канәгатьләндерә алмый.

Моннан нинди нәтиҗә ясарга кирәк? Һәрбер колхозда транспорт инвентаре ясый һәм ремонтлый торган махсус звенолар оештыру өчен тулы мөмкинлекләр бар. Колхоз председательләре һәл авым советлары бу эш турында яхшылап уйларга тиешләр.

*С. САФИУЛЛИН.*

# КОЛХОЗЛАРГА КАРАТА ДӘГВАЛАРНЫ КАРАУДА ХАЛЫК СУДЛАРЫ

Колхозлар һәм колхозчылар турында партиябез һәм хөкүмәтебез өзлексез кайгыртучанлык күрсәтәләр. Совет власте колхозларны экономик яктан ныгыту теләге белән аларга төрле льготалар һәм өстенлекләр бирә.

Колхозлар, юридик лицо буларак, башка социалистик оешмалар белән чагыштырганда яңа һәм яш оешмалар булып торалар. Суд процессларында үзләренең мөлкәт хокукларын яклау өчен аларның квалификацияле юрист кадрлары, юрист - консультлары юк. Аларның счет—бухгалтерия аппараты работникларының да квалификациясе җитәрлек түгел әле. Шунлыктан, колхозның тәҗрибәсез вәкиле судта иң гади дәгвалар буенча да бәхәсләшә алмый һәм бәхәсләрне тулы итеп нигезли алмый, ә каршы якның вәкиле, гадәттә квалификацияле юрист-консульт яки тәҗрибәле бухгалтер буларак, колхозның бу йомшак ягыннан файдаланып калырга, барлык чаралар белән дәгваны „отарга“ тырыша. Шулай итеп, якларның көчләре тигез булмаганда, суд тарафыннан эшне карауга җитәрлек игтибар бирелмәгәндә һәм формаль якын килгәндә суд карарларында колхозларның мөлкәт интересларына зарар китерүгә алып бара торган ялгышларга юл куела. Колхозларга карата бирелгән дәгваларны карауда халык судларының эш практикасында мондый ялгышлар аз түгел. Моны конкрет мисальләрдә күрсәтергә мөмкин.

Юллар төзү планын үтәмәгән өчен юл төзү органнары тарафыннан колхозларга карата бирелгән дәгваларны алып карыйк. Бу дәгваларның суммасы меңнәрчә сум тәшкил итә. Мәсәлән, Яңа Чишмә районында биш эш буенча гына да 101 мең 121 сумлык, Юдино районында 17 эш буенча 110.119 сумлык дәгва бирелгән. Бу районнарның халык судлары колхозлар өстеннән бирелгән эшләрне өстән генә караганнар, дәгваларны законсыз канәгатьләндергәннәр. Мәсәлән, Юдино районы халык суды „Привет труда“, „Свобода“, „Актив“, „8 нче Март“ һәм башка колхозларга карата бирелгән дәгвалар буенча юл төзү бүлеге файдасына 10 мең сумнан артык акча түләтү турында карар чыгарган. Чынлыкта исә юл төзү бүлеге, закон буенча билгеләнгән срок (срок давности) үтеп киткәнлектән, дәгва бирергә хокуклы да булмаган.

Яңа Чишмә районы халык судының карарлары белән эш тагын да начаррак тора. Ул, юл төзү бүлеге тарафыннан 5 колхозга карата бирелгән 101.121 сумлык дәгваны 56.363 сум күләмендә шушы колхозлардан түләтергә карар чыгарган. Бу карарлар барсы да диярлек законга нигезләнмәгән. Шунлыктан, халык суды тарафыннан чыгарылган карарларны юкка чыгару һәм төзәтү өчен эшләрне югары суд органнары карамагына бирергә кирәк булды.

Халык судларының бу өлкәдәге җитешсезлекләренә тагын шуны өстәргә кирәк. Колхозларга карата юл бүлекләренең дәгваларын карауда суд органнары ашыгучанлык күрсәтәләр, колхоз вәкилләренең аңлатмаларына тиешенчә игтибар бирмиләр. Нәтиҗәдә, нигезле сәбәпләр дә тикшерелмичә калалар. Судларның эшендәге мондый практика, һич шиксез, ялгыш карарлар чыгаруга китерә. Мәсәлән, Юдино районы халык судында эшне караганда „8 нче Март“ колхозының вәкиле күп кенә колхозчыларның колхоздан производствога эшкә киткәнлекләре, ләкин аларның юл төзү эшендә эшләргә тиешле кешеләр исемлегеннән чыгарылмаган булулары турында судка белдергән. „Свобода“ колхозы вәкиле, юл төзү эшеннән азат ителгән күп кенә колхозчыларның юл төзү эшен үтәргә тиеш булган колхозчылар исемлегенә кертелгән булулары турында белдергән. Колхоз вәкилләренең бу белдерүләренең эш өчен гаять зур әһәмияте булуга да карамастан, алар суд тарафыннан тикшерелмәгәннәр һәм суд бу эшләр буенча дәгваларны канәгатьләндерү турында дөрес булмаган карар чыгарган.

Юл төзү планын үтәмәгән өчен колхозларга карата дәгва бирү эшенә юл төзү бүлекләренең кайбер работниклары җавапсыз, формаль рәвештә һәм өстән генә карыйлар. Алар юл төзү буенча колхозларда эшне үрнәк рәвештә оештыру һәм юл төзү планын вактында үтәү өчен көрәшү урнына, колхозларны массовый рәвештә суд җаваплылыгына тарту, алардан акча түләттерү юлына басалар. Яңа Чишмә район юл бүлеге „12 лет Октября“ колхозына карата бер эш буенча гына да 39.428 сумлык дәгва биргән. Бу факт юл бүлегенең эшлексезлеге һәм дәгвалар бирүгә җавапсыз каравы турында сөйләмиме соң? Әлбәттә, шул турыда сөйли.

Дәүләт, юл төзү эшләрен үтәмәгән өчен колхозлардан акча түләттерү белән түгел, киресенчә, юл төзү планының үтәлеше белән кызыксына. Моны аңларга кирәк. Юл төзү планын үтәмәгән өчен колхозларны материаль җаваплылыкка тарту—ул, төп теләк түгел, бәлки юл төзү планын үтәү өчен көрәш средстволарының берсе. Шунлыктан, аны колхозның финанс хуҗалыгына удар ясау коралы итәргә кирәкми. Эш һәр хәлдә, материаль җаваплылыкны колхозга йөкләүгә кайтып калмаска тиеш. Суд органнары юл төзү эшләренең кем гаебе буенча өзелгәнлеген ачарга, гаепле кешеләрне табарга һәм, кирәк булса, уголовный тәртиптә җаваплылыкка тартырга тиешләр.

Халык судларының тиешле законнарга туры китереп чыгарган карарларын үтәгәндә кайбер колхоз правлениеләре тарафыннан законнарны бозу фактларын да күрсәтеп үтәргә кирәк. Мәсәлән, Октябрь районының „Победа“ колхозында шундый хәл була: юл төзү планын үтәмәгән өчен колхоздан 3.146 сум түләттерү турында халык суды карар чыгарган. Закон буенча бу акчаны юл төзүдә катнашырга бурычлы булган колхозчылар түләргә тиеш була. Ләкин „Победа“ колхозында ул акчаны колхоз членнарының барсыннан да түләтү турында „карар“ биргәннәр. Нәтиҗәдә, закон буенча юл төзү эшеннән азат ителгән күп кенә колхозчылар да аны түләүгә тартылганнар. Шуңа ошашлы факт бу районның „Ленинский Путь“ колхозында да булган.

Дәгваларның икенче төрен ягни колхозлар белән кооператив оешмалары һәм хосуси кешеләр арасында төзелгән договорлардан килеп чыга торган төрен алып карыйк. Әйтергә кирәк: бу дәгвалар буенча да шулай ук күп кенә хәлләрдә колхозларның мөлкәт интересларына зарар китерелә. Моның сәбәбе, барыннан да элек, колхозларның башка оешмалар һәм аерым кешеләр белән договорлар төзү практикасын үз агымына куюда, бу эшкә һич кем тарафыннан да контроль булмауда. Яңа Чишмә районының икенче участкы халык суды практикасыннан бер мисаль китерик.

1939 нчы елның җәендә „Александровка“ колхозы колхозда төзелеш буенча кайбер эшләрне башкару өчен ялгыз хуҗалыкчы Н. Горячев һ. б. (барсы өч кеше) белән договор төзи. Договорда, башкарылган эш өчен 1.000 сум акча һәм яңа уңышны суга башлау белән үк 150 пот ашлык бирү турында күрсәтелә. Горячев тарафыннан договор тиешенчә үтәлми. Шулай булуга да карамастан, Горячев 1.000 сум акча һәм 150 пот ашлык сорап „Александровка“ колхозына карата дәгва бирә. Халык суды бу эшне 29 нчы сентябрьдә карап, дәгваны канәгатьләндерергә дип, карар чыгара. Судның бу „карары“ турында колхоз тарафыннан жалоба бирелмәгән һәм ул бик тиз үтәлгән.

Бу эшне карауга судның чиктән тыш өстән генә якын килүенә кагылмастан (эшнең үтәлеше тикшерелмәгән, техникның белдерүенә караганда эш бары 40 процентка гына үтәлгән), түбәндәге әһәмиятле мәсьәләләр халык суды тарафыннан читләтеп үтелгәнлеген әйтергә кирәк. Договорның Горячевка 150 пот ашлык бирү турындагы пункты законсыз, чөнки ул авыл хуҗалыгы артеле Уставына һәм ашлык тапшыру турындагы законга каршы килә. Авыл хуҗалыгы артеленең Уставы һәм ашлык тапшыру турындагы закон буенча беренче сугылган ашлык дәүләткә тапшырылырга тиеш. Икенчедән, закон таләпләренә туры килмәгән договорга таянып, дәгваны канәгатьләндерү—ул, ялгыз хуҗалыкчыларны колхозлардан өстен кую дигән сүз. Халык суды моны „күрмәгән“ һәм бу эшкә тиешле политик бәя бирмәгән. Мондый һәм шуңа ошашлы фактларны күп кенә китерергә мөмкин.

Колхозларның хокук положениесен ныгыту проблемасы җитәрлек эшләнмәгән әле. Юстиция органнары, шул исәптән адвокатура тарафыннан колхозларга юридик ярдәм җитәрлек күрсәтелми. Колхозларга карата бирелгән дәгвалар буенча прокуратура органнары работниклары суд процессларында җитәрлек катнашмыйлар, халык судларының ялгыш карарларына протестлар җитәрлек түгел.

Колхозларга карата дәгваларны карауда халык судларының эшендә булган бу җитешсезлекләрне тамрыннан бетерергә кирәк. Суд һәм прокуратура органнары, шулай ук адвокатура колхозларның интересларын чын саклаучы булырга һәм шуның белән алар колхозларның тагын да үсүенә һәм колхозчыларның таза тормышлылыгының тагын да чәчәк атуына ярдәм итәргә тиешләр.

*Н. М. Шумилов.*

Татарстан АССР Юстиция Халык Комиссары урынбасары.

БҮГЕН—ХАЛЫКАРА КОММУНИСТИК ХАТЫН-КЫЗЛАР КӨНЕ

# СОЦИАЛИСТИК ВАТАННЫҢ ЯЛКЫНЛЫ ПАТРИОТКАЛАРЫНА СӘЛАМ!

## МЕҢНӘРНЕҢ БЕРСЕ

Пөхтәлек һәм җыйнаклык өстенә эшчән җиддилек, фикернең ачыклыгы, мәсьәләне сугыш обстановкасындагы кебек тиз һәм дөрес хәл кыла белү—Виктория Исаевна Черниковада менә бу сыйфатларның барсы да бергә тупланган.

— Менә,—ди иптәш Черникова,—данлыклы Кызыл Армиябезнең тормышы бик кызыксындыра иде, һәм мин үз теләгемә ирештем. 1932 нче елдан башлап армия сафларында эшли башладым.

1936 нчы елны тормышымда зур вакыйга булды. Бу елны мине Кызыл Армия командирлары һәм начальниклары составы хатыннарының Москвада чакырылган беренче Бөтенсоюз киңәшмәсенә делегат итеп сайладылар. Кремльдә булу, бөек юлбашчыбыз иптәш Сталинны күрү бәхтенә ирештем. Киңәшмәнең мандат комиссиясендә эшләдем. Иптәш Сталин һәм партия, хөкүмәт җитәкчеләре алдында мандат комиссиясе исменнән доклад ясадым.

Бу тарихи киңәшмәдә катнашучыларны хөкүмәт Союз орденнары белән бүләкләде. Бүләкләнүчеләр арасында мин дә бар идем. Мин „Хезмәт кызыл байрагы“ ордены белән бүләкләндем.

Иптәш Черникова 1932 нче елдан бирле Казанда эшли. Казан Кызыл Армия Йорты работнигы буларак, ул Кызыл Армия командирларын һәм сугышчыларын политик яктан тәрбияләүдә зур эш башкара. Ул үзенең политик белемен күтәрү өстендә дә зур тырышлык белән эшли. Данлыклы партиябезнең тарихын үзлегеннән өйрәнә. Бер үк вакытта ВКП(б) тарихын өйрәнүчеләр түгәрәгендә пропагандист булып эшли.

Кызыл Армия Йортында 4 политик түгәрәк эшләп килә. Халыкара хәл турында һәм башка темаларда докладлар, лекцияләр үткәрелә. Үзешчәнлек сәнгате түгәрәкләре тәртипле рәвештә планны эш алып баралар. Кызыл Армия командирларын һәм сугышчыларын тәрбияләү өлкәсендә алып барыла торган бу зур эшләрне оештыруда, аңа җитәкчелек итүдә партия оешмасының, аерым алганда, аның секретаре иптәш Черникованың роле гаять зур.

Кызыл Армиянең кадр составында хезмәт итүче батыр хатын-кызларның берсе—орденлы Черникованың эше, аның тормышы бик күпләр өчен үрнәк булырлык.

*Р. Н.*

## БИСТӘ КЫЗЫ

Без Сәлимә белән балачакта
Гөл үстерә идек икәүләп.
Без ярыша идек: аның гөле
Чәчәк ата иде иртәрәк.

Якты кояш нурларына куеп,
Без гөлләрне кадерли идек,
Тәмле исле гөлләр арасында
Бергә дәрес хәзерли идек.

Суык булса иртә, кичләрдә
Саклый идек салкын тиүдән,
Саклый идек күрше-тирәдәге
„Карак кәҗә“ ашап китүдән.

Менә шулай бала чагында
Гөл үстерә идек кадерләп,
Кызыл чәчәк аткан гөлләребез
Әлегедәй минем хәтердә.

* * *

Бәхетлеләр булып үстек без
Ватаныбыз Совет җирендә,
Врач булды безнең Сәлимә
Үзе үскән туган илендә.

Икебез дә бер бистәдә үстек,
Икебез дә хезмәт кызлары,
Икебез дә без бәхетле үстек,
Икебез дә Ватан кызлары.

Бергә үскән дустым, бистә кызы
Сәлимәкәй хәзер еракта,
Туган илне сөеп Сәлимәкәй,
Врач булып китте фронтка.

Мин хат алдым якын дустымнан
Финляндия сугыш кырыннан,
Туган илнең яхшы врачы—
Комсомолка хезмәт кызымнан.

„—Сәлам сезгә!—дигән Сәлимәкәй,—
Тыныч - рәхәт хезмәт итегез,
Илне саклый Кызыл Армиябез,
Һич югалмас безнең иркебез.

Һичбер төрле дошман этләре
Таптый алмас безнең гөлләрне,
Чөнки безнең гөлләр җир шарында
Азатлык һәм бәхет үрнәге.

Финляндия хезмәт халыкларын
Ак финнәрдән азат итәрбез,
Без азатлык яклап сугышабыз,
Без халыкка бәхет бирәбез.

Без белмибез һич тә җиңелүне,
Без бары тик җиңә беләбез,
Финляндия хезмәт халкы белән
Тиздән бергә бәйрәм итәрбез“.

Сәлимәнең хатын укыгач,
Искә төште үткән көннәрем,
Хәтерләдем бистә кызының
Кызыл чәчәк аткан гөлләрен.

Икебез дә бер бистәдә үстек,
Икебез дә хезмәт кызлары,
Икебез дә без бәхетле үстек,
Икебез дә Ватан кызлары.

*Әминә Бикчәнтәева.*

## Хатын-кызлар җаваплы эшләргә күтәреләләр

Кызыл Армия районында җаваплы эшләргә күтәрелүче хатын-кызларның саны көннән-көн арта.

Соңгы вакытта 5 кеше колхоз хисапчылары итеп, 3 кеше бригадирлар итеп, 10 кеше уку өе һәм клуб мөдирләре итеп һәм 19 кеше партия, комсомол, совет эшләренә күтәрелде.

Элек райкомда техсекретарь булып эшләгән иптәш Гыйззәтуллина Шәрифә ВКП(б) райкомының оештыру-инструкторлык бүлеге мөдире итеп күтәрелде. Партикабинет китапханәчесе иптәш Мифтахетдинова Мәдинә хәзер ВКП(б) райкомының учет эшләре бүлеге мөдире булып эшли.

„Комбайн“ колхозында түбәннән күтәрелгән иптәш Габбасова Кәшифә җитәкчелегендәге бригада язгы чәчүгә хәзерлекне тулысынча тәмамлады.

Бригада членнары 1940 нчы елны һәр гектардан 100 пот иген уңышы алу өчен көрәшәләр. (ТатТАСС).

## Спорт мастеры Шангина

— Әнә, әнә, тагын уза, шул булыр беренче урында, шул!—ди спартакчыларның берсе. Хатын-кыз физкультурникларның 5 километрга чаңгыда узышулары Казанка буеннан бик матур—ачык булып күренә. Һәр 15 секундтан соң бирелгән старт вактында ук халык 86 нчы номерны билгегә алды. Кояш яктылыгында балкып торган кызыл сатин күлмәк, кызыл башлык кигән чаңгычы старттан ук бик кызу темп белән чыгып китте. Аның артыннан җил уйнап кала, чаңгылары астында „чажж-чожж“ килеп кар шытырдый. Старттан 200 метрлар чамасы китү белән инде ул үзеннән алдагыларын уза башлый.

— 86! Шангина! Катя Шангина!—дип кычкыралар һәм кечерәк буйлы, тыгыз гәүдәле яш спортчы финишкә килеп керә.

Судьялар 5 километрга Шангинаның беренче урынны алганлыгын, шушы дистанциягә Казан чемпионы булуын игълан итәләр. Юлда уннарча кешеләрне үтә-үтә ул 24 минут 44 секунд эчендә 5 километрны артта калдыра.

— 24 минут эчендә 5 километр!

Иптәш Шангина үзенең улы Юра белән

Казанда бу дистанциягә быелгы ярышларда күрсәтелгән иң яхшы нәтиҗә. Йөзләрчә кешеләр Катяга карап елмаялар, аны уңыш белән котлыйлар. Ә Катя, аеруча бер нәрсә дә булмагандай гадилек белән, үзенең улы Юра янына килеп аны кулына ала. Алар икәүләп елмаялар.

Казанда спорт-физкультура яратучылар арасында бу таза, чыныккан ананы белмәгән кеше юк. Казанда гына да түгел. Автономияле 9 республика спартакиадаларын караган меңнәрчә кешеләр аның осталыгын инде соклану белән берничә тапкыр күзәттеләр.

Ә узган җәйне Харьков шәһәрендә, орденлы „Спартак“ спорт җәмгыятенең Бөтенсоюз ярышларында Катя спортның җәйге төрләре буенча иң яхшы нәтиҗә күрсәтеп, СССР ның спорт мастеры дигән исемне яулап алды. Шулай итеп, Казанда беренче мастер барлыкка килде. СССР ның спорт мастеры булу өчен һәр яктан чыныккан, илнең оборонасына һәм хезмәткә бөтен магнәсе белән хәзер булырга һәм мастер өчен булган нормаларны үтәргә кирәк. Ә Катя җиңел итеп йөгерә, яхшы сикерә, сөңгене, гранатаны, дискыны һәм ядроны еракка ыргыта белә.

Орденлы „Динамо“ җәмгыятендә көрәшче спортчы коммунист Крюков җитәкчелегендә, ә аннан соң „Спартак“ җәмгыятендә оста тренер Кашаев җитәкчелегендә безнең Шангина югары классның җиңел атлет булып өлгерә. „Спартак“ члены булган хәлдә йөзләрчә спартакчыларны, Химия-Технология институтының физкультура укытучысы булган хәлдә күп сандагы студентларны ул спорт осталыгына өйрәтә, үзенең тәҗрибәләрен алар белән уртаклаша.

Ул өйрәткән Нина Цветкова, Т. Кладнева, Клара Абдрашитова, Зәйнәп Гыйлаҗеттинова һәм башка бик күпләр инде яхшы спортчылар булып өлгереп киләләр. Ә спартакчы Нина Савощенко, әле шушы көннәрдә генә булып үткән бөтен шәһәр ярышларында чаңгыда 10 километрга булган узышта беренче урынны алып, хәттә Катяның үзен дә уздырып җибәрде.

Киләчәктә аларның мастерлар булачакларын күреп Катя шатлана.

— Бәхетле илебезнең бәхетле кызлары арасында йөзләрчә мастерлар үсә,—ди.

Катя ату спортын да яхшы итеп үзләштергән. Мөмкин булган 50 очкодан ул 42—43 очко җыя.

— Әгәр дә кирәк була икән, кулыма мылтык алырга, кадерле Ватаным өчен, физкультурникларның иң яхшы дусты сөекле Сталин өчен сугыш мәйданында теләсә нинди дошманга җимергеч отпор бирергә, данлыклы Кызыл Армиянең тырыш сугышчысы булырга мин хәзер,—ди Катя.

*Г. Хәбиб.*

## Җитен комбинатында тәрбияләнгән кешеләр

Казан җитен комбинаты эшчеләре коллективы хатын-кызларның гүзәл армиясен тәрбияләде. Галия Измайлова комбинатта яхшы тәрбия алды. Ул өйрәнчек булып эшли башлады. Аннары производство алдынгылары арасында ныклы урынны алды. Энергияле һәм сәләтле коммунист сыйфатында аны партия оешмасы секретаре итеп сайладылар. Хәзер ул—Татарстан АССР Верховный Советы депутаты, Татарстанның җиңел промышленность халык комиссары.

Ата-бабалары һәм үзе тукучы булган Хәйрикамал Төхфәтуллина—СССР Верховный Советы депутаты. Ул да рядовой эшчедән дәүләт эшлеклесе булып үсте.

Комбинатның хатын-кызларыннан 5 стахановчы узган ел Советлар Союзы орденнары һәм медальләре белән бүләкләнделәр. Бригадир Гаян иптәш **Әхмәдуллина** „Почет билгесе“ ордены белән, стахановчы **Бурлакова, Шәрәфеттинова, Иванова** һәм **Малова** иптәшләр „Аеруча хезмәт күрсәткән өчен“ медале белән бүләкләнделәр.

Коллектив үзенең иң яхшы вәкилләреннән 12 хатын-кызны шәһәр һәм район Советларына депутатлыкка кандидат итеп күрсәтте. Сайлаучылар комбинат коллективының бу теләген бердәм рәвештә яклап, җитен комбинатының иң яхшы хатын-кызларын шәһәр Советына һәм Киров райсоветына депутат итеп сайладылар.

Хатын-кызлар барлык урыннарда да хезмәткә социалистик караш үрнәкләре күрсәтәләр. Коллектив намуслы эшкә чын күңелдән бирелгән кешеләрне җитәкче постларга күтәрә. Мәсәлән, стахановчы иптәш Минһаҗева моннан ике ай элек мастер итеп, ФЗӨ мәктәбе инструкторы иптәш Фәхреттинова производство өйрәтүләре бүлеге мөдире итеп, тарау цехы эшчесе иптәш Сурина клуб мөдире итеп күтәрелделәр.

(ТатТАСС).

## ИРЕШКӘН УҢЫШЛАР БЕЛӘН ТУКТАЛЫП КАЛМАМ

Заводка килгәндә минем бер төрле дә квалификациям юк иде. Станоклар тавышы, станоклардан чыккан ялтыравыклы тимер йомычкалары, шат йөзле гади эшчеләр миндә ниндидер тәэсир калдырдылар. Цех шунда ук миңа бик якын булып тоелды. Мин укырга өйрәнергә керештем.

Безне, яңа килгән эшчеләрне дусларча игтибар белән чолгап алу заводта уңышлы эшләүгә өмет тудырды. Стахановчы комсомолец иптәш Харисов миңа һәр вакыт ярдәм итә иде.

Мин фрезер станогында эшли башладым. Өченче разрядка күтәрелдем. Хәзер миңа 5 нче разрядтагы эшләрне дә тапшыралар. Шуңа да карамастан, мин норманы арттырып үтим. Узган айда планны 200 процент итеп үтәдем. Быел тагын да зуррак уңышларга ирешү өчен көрәшәм.

Безнең цех эшчеләре арасында кызлар аз түгел. Комсомолка иптәш Николаева яхшы слесарь. Шуның белән бергә ул бер профессия белән генә канәгатьләнмәде, затыловка станогын да үзләштерде. Бу барыбыз өчен дә гүзәл үрнәк булып тора.

Серго Орджоникидзе исемендәге заводның фрезеровщигы.

*Г. Бәширова.*

## 25 мең сум пособие

Миңа әле бары 33 яшь, ә инде минем 11 балам бар. Совет хөкүмәте, большевиклар партиясе һәм иптәш Сталин күп балалы аналар турында чын-чыннан кайгырталар. Күп балалы аналарга ярдәм итү турында закон чыкканнан бирле мин 25 мең сум пособие алдым. Бер быел гына да дәүләт миңа 12 мең сум пособие бирәчәк. Шуның 5 мең сумын алдым инде.

Минем балаларым мохтаҗлык һәм кайгы күрмичә үсәләр. Олы улым Александр, икенче улым Михаил 4 нче класста яхшы билгесенә, кызларым Валентина һәм Надежда 3 нче класста отлично билгесенә, өченче кызым Зинаида икенче класста яхшы билгесенә укыйлар.

Семьябездә культуралы тормыш алып барабыз: патефоныбыз, балалайкабыз, тегү машинабыз бар. Үзәк һәм өлкә газеталары, журналлар алабыз, аларны укып илебезнең тормышы белән һәм халыкара хәл белән танышабыз.

Без, совет хатын-кызлары, Сталин эпохасында яшәвебез белән бәхетлебез. Мин үземнең балаларым белән мактанам. Иптәш Сталин кешеләрне барлык нәрсәдән дә кыйммәтрәк күрә. Бездә бала анасы булу зур шатлык, ана исеме—горур исем!

Безнең семья, аналар һәм балалар турында өзлексез кайгырту өчен партиягә, хөкүмәткә һәм иптәш Сталинга бик зур бурычлы. Без үз балаларыбызны Ватаныбызның кайнар патриотлары итеп тәрбияләрбез!

*Мария Хохлова.*

Теләче районының Тельман исемендәге колхозы члены.

Казан аэроклубында. РӘСЕМДӘ (сулдан уңга): пилот-инструктор иптәш М. Малышкина яш очучы К. Зуева, Р. Савинова һәм В. Левченко иптәшләр белән занятие үткәрә. Л. Попов фотосы (ТатТАСС фотохроникасы).

# БӨЕК ИДЕЯЛӘР ТАНТАНАСЫ

СССР хезмәт ияләре Халыкара Коммунистик Хатын-Кызлар Көнен хатын-кызларны азат итү турында Маркс, Энгельс, Ленин, Сталинның бөек идеяләренең тантанасы көне итеп бәйрәм итәләр.

Безнең илебездә Бөек Октябрь Социалистик революция җиңгәч тә, Совет власте хатын-кызларның азатлыгын игълан итте. Сталин Конституциясе хуҗалык, дәүләт, культура һәм җәмагат тормышының барлык тармакларында хатын-кызларның ирләр белән тигез хокуклылыгын беркетеп куйды.

Сталин Конституциясенең 122 нче статьясендә болай диелә:

„СССР да хуҗалык, дәүләт, культура һәм иҗтимагый-политик тормышның барлык өлкәләрендә дә хатын-кызга ирләр белән тигез хокуклар бирелә.

Хатын-кызларның бу хокукларын тормышка ашыру мөмкинлеге, хезмәткә, хезмәт хакы алуга, ял итүгә, социаль страхованиегә һәм белем алуга хатын-кызларга ирләр белән тигез хокук бирү белән, ананың һәм баланың интересларын дәүләтнең саклавы белән, йөкле вакытта хатыннарга хезмәт хакын саклап отпуск бирү белән, бала тудыру йортларының, балалар яслеләренең һәм бакчаларының киң челтәре белән тәэмин ителә“.

Безнең илебезнең хезмәт ияләре 8 нче Март көнен зур уңышлар белән каршылыйлар. СССР да социализмның җиңеп чыгуы производствода һәм политик тормышта хатын-кызларның киң күләмдә катнашулары өчен кирәкле шартларны тудырды. Промышленностьның барлык тармакларында хатын-кызлар команда югарылыкларына кадәр күтәреләләр. СССР да хатын-кызлардан инженер-техник работникларның саны 1937 нче елда ук 98 мең кешегә җитте. Бездә хатын-кызлардан очучылар, бортмеханиклар, радистлар, врачлар, шоферлар, тракторчылар һәм башка шундый профессияләрне үзләштерүчеләр бик күп. Безнең орденлы Татарстан республикасында гына да 979 хатын-кыз врач бар.

Хәзерге көндә Татарстанның барлык предприятиеләрендә эшче хатын-кызлар Татарстан АССР ның XX еллыгы исемендәге социалистик ярышка кушылдылар. Алар социалистик хезмәткә чын күңел биреп карауның гүзәл үрнәкләрен күрсәтәләр. Казан шәһәре язу машиналары заводының стахановчысы, инструменталь цехы слесаре иптәш Б. Камалиева үзенең нормасын системалы рәвештә 160—170 процент үтәп килә.

Җитен комбинаты стахановчыларыннан А. Столярова, Демидова, Михеева, Тарасова һәм башка иптәшләр производство планын системалы рәвештә арттырып үтиләр. Иптәш Столярова цех мастеры итеп күтәрелде. Җитен комбинаты коллективы ярты еллык планны Татарстанның XX еллыгына (25 нче июньгә) 110 процент итеп үтәргә йөкләмә алды.

Җитен комбинаты эшчеләре составында күпчелеге хатын-кызлар. Алар үзләренең нормаларын арттырып үтәү һәм яхшы сыйфатлы продукция бирү өчен большевистик көрәш алып баралар.

1 нче тегү фабрикасының комсомолкалары һәм яшьләре 8 нче Март көнен производствода яңа уңышлар белән билгелиләр. Инструктор иптәш Хәйреттинова хезмәтне дөрес оештыруда һәм социалистик ярышны җәелдерүдә зур инициатива күрсәтә. Комсомолкалардан Маратова, Нәҗмиева иптәшләр көнлек нормаларын һәр вакыт 170—180 процент итеп үтиләр. 6 нчы һәм 12 нче группаларда эшләүчеләрдән Фәхреттинова, Сафина, Фәттахова иптәшләр дә үзләренең нормаларын арттырып үтиләр һәм һәр вакыт бик яхшы сыйфатлы продукция бирәләр.

Хатын-кыз яшьләр оборона эшендә дә актив катнашалар. Зарипова, Александрова, Малышкина иптәшләр Казан аэроклубы янындагы очучылар мәктәбен тәмам итеп чыктылар. Алар самолет төзелешен бик яхшы өйрәнделәр. Иптәш Малышкина соңгы вакытта Ульяновскидагы пилотлар мәктәбен тәмам итеп чыкты.

Осоавиахим мәктәпләрендә күп кенә хатын-кызлар ат өстендә йөрергә, ату спортына өйрәнәләр. Күп кенә кызлар „Ворошиловча атучы“ значогына норма тапшырдылар. 1939 нчы елда гына да хатын-кызлардан 2.124 кеше „Ворошиловча атучы“ значогына норма тапшырды. Күп кенә хатын-кызлар пулеметны өйрәнделәр. Бездә шулай ук хатын-кызлардан күп кенә парашютчылар хәзерләнде.

Ленин—Сталин партиясе промышленностьта, авыл хуҗалыгында, советларда һәм профсоюзларда хатын-кызларны команда постларына кыюлык белән күтәрә. Безнең илебездә 10 меңнән артык хатын-кыз колхоз председателе һәм председатель урынбасары булып эшли. Узган җәй Татарстан МТС ларында хатын-кызлардан 738 тракторчы, 208 комбайнчы эшләде, 15 кеше трактор бригадаларының бригадиры булып эшләде.

Күп кенә хатын-кызлар колхозларда зур активлык белән эшлиләр. Теләче районының „Новая Жизнь“ колхозында комсомолкалардан Читнеева, Комарова, Бәширова иптәшләр һәм башкалар кар тоту, чәчүлек орлыкларны туплау, көл җыю эшләрен үрнәк булырлык итеп башкаралар. Алар агротехника чараларын үткәрү өчен үз тирәләренә күп кенә яшьләрне туплаганнар. Шул ук районның „Чулпан № 2“ колхозында стахановчы иптәш Шәрифуллина җитәкчелегендә звено төзелгән. 7 кешедән торган бу звенога 22 гектар җир участкысы беркетелгән. Звено 1940 нчы елда һәр гектардан 35 әр центнер иген уңышы, бодай чәчелгән 3 гектарлык рекордлы участкының һәр гектарыннан кимендә 50 шәр центнер уңыш алу бурычын үз алдына куйган. Звено членнары агротехника чараларын үткәрүдә зур тырышлык күрсәтәләр.

Безнең илебездәге хатын-кызлар дәүләтне идарә итүдә актив катнашалар. СССР Верховный Советына безнең республикадан 7 хатын-кыз депутат итеп сайланды. Алар арасында Төхфәтуллина, Хәбибрахманова, Нуриҗанова, Ромашкина иптәшләр һәм башкалар бар. РСФСР Верховный Советына Татарстаннан 3 хатын-кыз, ТАССР Верховный Советына 25 хатын-кыз депутат итеп сайланды. Авыл, район һәм шәһәр советларына хатын-кызлардан сайланган депутатларның саны 2 меңнән артык. ВЛКСМ ның Татарстан оешмасы сафларында член булып торган хатын-кызларның саны 40 меңнән арта.

Совет хатын-кызы өчен барлык мәктәпләрнең, техникумнарның һәм югары уку йортларының ишекләре ачык. Безнең илебездә югары уку йортларында укучы хатын-кызларның саны гаять зур. Узган ел алынган мәглүматларга караганда, СССР ның югары уку йортларында укучы хатын-кызларның саны 43 проценттан артыграк булган. Казан шәһәренең югары уку йортларында хатын-кызлардан 5.098 кеше укый. Алар барлык студентларның 56,5 процентын тәшкил итәләр. Бу санга Казан Химия-Технология институтында һәм Казан Авиация институтында укучылар керми.

Совет власте аналар турында зур кайгыртучанлык күрсәтә. 1914 нче елда патша Россиясенең барлык больницаларында һәм бала тудыру йортларында бала тудыручы хатыннар өчен тик 6.800 генә койка булган. 1940 нчы елда безнең Татарстанда гына да бала тудыру йортларында һәм больницаларда бала тудыручы хатыннар өчен 1.260 койка бар. Балалар өчен 79 урында консультация, 30 урында сөт кухнясе оештырылды. Балалар яслеләрендә 13.175 койка бар. Балалар бакчаларында һәм мәйданчыкларда берничә унмеңләп бала тәрбияләнә. 1936 нчы елдан алып 1939 нчы елның 1 нче январена кадәр СССР да күп балалы аналарга дәүләт тарафыннан 2 миллиард сумнан артык пособие бирелде. Аналарны һәм балаларны саклау өчен 1937 нче елда дәүләт тарафыннан 4 миллиард сум расход тотылды. Татарстандагы күп балалы аналар 1939 нчы елда гына да дәүләттән 23 миллион 992 мең сум пособие алдылар.

Советлар Союзында 8 нче Март көне—барлык хезмәт ияләре өчен шатлыклы бәйрәм. Быел чит илләрдә 8 нче Март көне империалистик сугышка каршы, сугыш уты кабызучыларга каршы, Англия һәм Франция империалистларына каршы көрәш лозунгысы астында үтәчәк.

Көнбатыш Украинада һәм Көнбатыш Белоруссиядә СССР халыкларының туганлык семьясенә кушылган һәм азат булган хезмәт ияләре 8 нче Март көнен быел ирекле рәвештә бәйрәм итәләр.

Безнең бурыч—хатын-кызларны җитәкчелек эшенә кыюрак күтәрү, ВКП(б) һәм комсомол сафларына керүгә алдынгы хатын-кызларны киң рәвештә хәзерләү, оборона эшендә катнашуда һәм оборона техникасын өйрәнүдә хатын-кызларга тагын да зуррак мөмкинлек тудыру. Барлык хатын-кызлар үзләренең уяулыкларын тагын да күтәрергә, большевизмны үзләштерергә һәм социализмның куәтен ныгыту өчен тагын да зуррак энергия белән көрәшергә тиешләр.

Советлар иленең, шул исәптән орденлы Татарстанның хезмәт иясе хатын-кызлары Сталинчыл өченче бишьеллык планны уңышлы итеп үтәү өчен беренче сафларда көрәшерләр. Илебезнең хезмәт иясе хатын-кызлары Ленин—Сталин партиясенә чын күңелдән бирелгәнлекләрен, Бөек Октябрь Социалистик революциясенең казанышларын сакларга һәр вакыт хәзер торуларын 8 нче Март көнендә тагын бер тапкыр күрсәтерләр.

*Г. Шәмсиева.*

Татарстан АССР Верховный Советы депутаты.

## Зурларны укыту мәсьәләсе буенча республика киңәшмәсе

Укый-яза белмәүчелекне бетерү мәсьәләсе буенча 5—6 нчы мартта, республика киңәшмәсе булып үтте. Киңәшмәдә Тымытык, Кайбыч һәм Чепья районнарының халык мәгарифе бүлекләре мөдирләре үз районнарында укый-яза белмәүчелекне бетерү эшенең торышы турында доклад ясадылар.

Укый-яза белмәүчелекне тәмам бетерү турында партиябезнең һәм хөкүмәтебезнең күрсәтмәләрен тормышка ашыруда республикабызда шактый эш үткәрелде. 1939 нчы елны гына да 63 мең кеше үзенең укый-яза белмәүчелеген бетерде. Кайбер районнар тоташтан грамоталы район булу алдында торалар.

Ләкин беренче уңышлар безне һич тә канәгатьләндерә алмыйлар. Орденлы республикабызның данлыклы XX еллыгына республиканы тоташтан грамоталы итү өчен гаять зур эш таләп ителә. Республикада 73 мең укый-яза белмәүче һәм 200 меңнән артык аз укый-яза белүче барлыгын искә алу гына да бу эшнең нинди зур колач алырга тиешлеген бик ачык күрсәтә.

Ике көн буена дәвам иткән киңәшмә үз алдына куелган бурычны нигездә үтәсә дә, ләкин фикер алышуларда катнашучы күп кенә иптәшләр коры декларацияләр белән генә чикләнделәр. Алар үз районнарында укый-яза белмәүчелекне бетерүнең барышы турында сводкалар китереп, ахырда, укый-яза белмәүчелекне бетерү буенча йөкләмә алдылар. Йөкләмә алу бик яхшы эш, әлбәттә. Ләкин ул йөкләмәләр чынбарлыкны чагылдырырга, реаль булырга тиешләр.

Укый-яза белмәүчеләрне һәм аз укый-яза белүчеләрне укыту эше аерым урыннарда бик начар оештырылган. Мәсәлән, Сталин районында 977 кеше, Чепья районында 720 кеше укуга тартылмаган. Зурларны укыту мәктәпләре дәфтәрләр, уку китаплары белән тәэмин ителмәгәннәр. Мәктәпләрдә рус графикасы нигезендәге яңа алфавитта басылган китаплар юк һәм Наркомпрос моны булдыруны тизләтми.

Укый-яза белмәүчелекне тиз арада һәм тәмам бетерү өчен көрәшне Наркомпрос үзе дә бик начар оештыра. Зурлар мәктәбе управлениесенең һәм аның начальнигы иптәш Вәлиевнең „конкрет" җитәкчелеге сводка җыюдан һәм кәгаз җибәреп торудан ерак китә алмаган. Киңәшмәдә фикер алышуларда катнашучы иптәшләр моны бик дөрес күрсәттеләр һәм мондый практиканы бик урынлы тәнкыйтьләделәр.

Мәсьәлә ачык булса кирәк. Наркомпрос җитәкчеләре һәм РОНО работниклары мондый хәлгә большевикларча тулы анализ ясап, зурларны укыту эшен яхшырту буенча кискен чаралар билгеләргә тиешләр. Ләкин кайбер РОНО работниклары моны аңлап җиткермәгәннәр әле.

Укый-яза белмәүчелекне бетерү һәм аз укый-яза белүчеләрне укыту турында хөкүмәт тарафыннан күрсәтелгән сроклар күптән үттеләр инде. Партия, совет оешмалары һәм халык мәгарифе органнары бу гаять зур политик әһәмиятле эшкә үз игтибарларын көчәйтергә һәм укый-яза белмәүчелекне бетерү эшен республикабызның данлыклы XX еллыгына тулысынча тәмам итү өчен конкрет чаралар күрергә тиешләр.

*Рим Баһау.*

## Язгы чәчүгә хәзерлек һәм сәүдә оешмалары

Кыр эшләре башлануга күп калмады. Чәчүгә барлык тармаклар буенча яхшы хәзерләнү—мул иген уңышы алуны тәэмин итәчәк. Бу гаять әһәмиятле һәм җаваплы эшне уңышлы башкарып чыгу сәүдә оешмаларының һәм, беренче чиратта, Татсоюзның, райпотребсоюзларның язгы чәчү вактында үзләренең эшләрен үрнәк рәвештә оештыра белүләренә, киң куллану товарларына карата колхозчыларның сорауларын яхшы канәгатьләндерә алуларына бәйләнгән.

Дөресен әйтергә кирәк: райпотребсоюзларның һәм сельполарның күпчелеге язгы чәчүгә карата үзләренең эшләрен үзгәртеп кору эшенә әле чын-чынлап керешкәннәре юк. Татсоюзның үзендә дә бу эш канәгатьләнерлек куелган дип әйтеп булмый.

Оештыру бюросында кабул ителгән план нигезендә быел язгы чәчү вактына кадәр райпотребсоюзларга 4 миллион 122 мең сумлык производство һәм хуҗалык товарлары җибәрелергә тиеш иде. Ләкин бу план үтәлми. Планда күрсәтелгән товарлардан кыр кухнясе, казан, фонарь һәм башка күп кенә товарлар райпотребсоюзларга бөтенләй җибәрелгәннәре юк әле. 45 мең данә тимер көрәкнең бүгенге көнгә 300 данәсе, 8 мең данә балтадан 20 генә балта районнарга җибәрелгән. Производство һәм киң куллану товарларының үз вактында сельполарга җиткерелүе өчен барлык чараларны күрергә кирәк.

Урыннардагы промартельләрдә җитештерелә торган киң куллану товарлары белән сәүдә итүне бөтен киңлегенә җәелдереп җибәрү мәсьәләсе белән Татсоюз, шулай ук райпотребсоюзлар әле дә булса җитәрлек шөгыльләнмиләр. Шуның нәтиҗәсе буларак, моннан берничә ел элек уңышлы гына эшләп килгән һәм көпчәк, дуга, камыт агачы, күчәр, арба кебек әйберләр җитештерүче күп кенә производство артельләре хәзерге вакытта бөтенләй эшләмиләр. Узган ел планнан тыш хәзерләнгән товарлар белән сәүдә итү еллык сәүдә әйләнеше сумасының 3 процентын гына тәшкил итүен бары тик Татсоюзның, бигрәк тә аның сәүдә идарәсе җитәкчеләренең бу җаваплы эшкә җавапсыз карашлары белән генә аңлатырга мөмкин.

„Сез промышленностьны этәргә, алга алып барырга тиешсез. Сез промышленностьны һәм кустарьчылык - промысло кооперациясен халыкның сорауларын канәгатьләндерү өчен кирәк булган иң күп төрле товарлар эшләп чыгарырга, хәтта производствоның яңа тармакларын тудырырга мәҗбүр итәргә тиешсез".

Потребкооперация работниклары иптәш Калининның бу күрсәтмәләрен бер минутка да онытмаска, производство артельләре белән элемтәне ныгытырга һәм теге яки бу продукцияне җитештерү буенча артельләр белән алдан ук договорлар төзеп куярга тиешләр.

Дөрес, кайбер райпотребсоюзлар производство артельләрендә эшләнә торган товарлар белән сәүдә итүне яхшырту өчен кайбер чараларны күрәләр. Мәсәлән, Әгерҗе райпотребсоюзы (председателе иптәш Галләмев) планнан тыш товар хәзерләү өчен барлык чараларны күрә. Райпотребсоюз быел язгы чәчү вактына кадәр 1.000 данә чиләк, 100 данә кыр кухнясе, агач кашыклар һәм башка төрле күп кенә товарлар сатып алу турында районда булган артельләр белән договор төзеп, бу товарларны ала да башлады инде.

Әлмәт, Алабуга, Буденный райпотребсоюзлары язгы чәчү вактына кадәр арба көпчәге, дуга, агач кашык, чиләк, савыт-саба, бау, кыр кухняләре һәм башка төрле әйберләр җитештерү буенча урыннардагы производство артельләре белән договорлар төзеделәр.

Кырда эшләүче колхозчыларны көндә кирәк була торган товарлар белән тәэмин итү өчен язгы чәчү һәм аңа хәзерлек вактында өстәмә рәвештә 262 ларек, 921 разноска, 493 урында автомашиналар һәм атлар белән йөреп сәүдә итү оештырылачак.

Сельполарны, кибетләрне, шулай ук өстәмә рәвештә оештырылган сәүдә точкаларын киң куллану товарлары белән өзлексез рәвештә тәэмин итү өчен сәүдә работниклары орденлы Татарстанның XX еллыгы исмендәге социалистик ярышны киң җәелдерергә һәм язгы чәчү вактында колхозчыларга сәүдә хезмәте күрсәтүне үрнәк рәвештә оештыру өчен барлык чараларны күрергә тиешләр.

*Г. Рәхимев.*

Татсоюзның оештыру бюросы председателе урынбасары.

## Зурларны укыту эшен көчәйтергә

1939 нчы елның 1 нче мартына Теләче районында тоташ укый-яза белә торган 10 авылга дәүләт акты тапшырылган иде. Бу авылларда хәзер яңа алфавитны өйрәнү эше яхшы бара. Баландыш авыл советында 100, Тәмте авыл советында 160, Карбаян авыл советында 134 кеше яңа алфавитны өйрәнү курсларын тәмамлап чыктылар.

Шушы елның январь аенда районда тагын 5 авылда укый-яза белмәүчелек бетерелде. Хәзер бу авылларда яңа алфавитны өйрәнү эше киң җәелде. Кукчә, Янбулат авылларында инде 50 шәр кеше укытып чыгарылды.

Гомумән, район күләмендә алганда, зурларны укыту эшенең торышы мактарлык түгел. Районда укый-яза белмәүчеләр саны 810 кеше, шулардан укуга 313 кенә кеше тартылган. Аз белемлеләр саны 1.048 кеше, шулардан укуга 410 гына кеше тартылган. Зурларны мәктәпкә тарту һәм укыту буенча яхшы күрсәткечләр биргән алдынгы укытучылардан Комиссаров, Спиридонов, Яковлев, Солтанова, Агачова һәм башка иптәшләрнең эш тәҗрибәләрен уртаклашу оештырылмаган. Район мәгариф бүлегенең зурларны укыту буенча инспекторы иптәш Иванов авылларга барып, бу эшне урында оештыру һәм урындагы активистларга ярдәм күрсәтү урнына, канцелəриядән телефон аша сводка җыеп кына утыра.

(ТатТАСС).

## Хатын-кызларның производстводагы уңышлары

Чистай районының хатын-кызлары 8 нче Март Көнен производствода яңа уңышлар белән каршылыйлар. Шәһәрдәге предприятиеләрдә һәм районның колхозларында йөзләрчә стахановчылар үзләренең заданиеләрен арттырып үтиләр. Судноларга ремонт ясау заводының электросварщигы иптәш Козлова көн саен ике норма бирә.

Район һәм шәһәр советларының депутатлары: күн заводы эшчесе Шахмаева, аракы заводы эшчесе Беляева, „Красный двигатель" заводының фрезерчысы Козырева һәм башка күп кенә иптәшләр нормаларын системалы рәвештә 150—200 процент итеп үтиләр. Вахитов исмендәге, „Урожай", Андреев исмендәге колхозларда һәм Галактионов исмендәге совхозда уннарча кызлар тракторны өйрәнәләр.

Судноларга ремонт ясау заводында һәм башка күп кенә предприятиеләрдә ирләр профессиясен үзләштергән хатын-кызлар хәзер тимерче, электросварщик, буяучы булып эшлиләр. Судноларга ремонт ясау заводының чүкеччесе иптәш Титова норманы 130—150 процент итеп үти. Балалар бакчасы тәрбиячесе комсомолка иптәш Клюканова күптән түгел очучылар курсын тәмамлады һәм запастагы пилот исмен алды.

(ТатТАСС).

## Санитария кадрлары

Сталин районының РОКК Комитеты хатын-кызлардан медицина сестралары, санитария дружиначылары һәм ГСО значкистлары хәзерләүгә зур әһәмият бирә. Районда 3 урында медицина сестралары хәзерләү курслары эшли. Курсларда укулар производстводан аерылмыйча алып барыла.

8 нче Март бәйрәменә 2 санитария дружинасына (Жиркомбинат һәм Мехкомбинат янындагы дружиналар) чыгарыш үткәрелә. Дружиналарны 45 кеше тәмамлап чыга. Аларның күбесе сынауларны отлично һәм яхшы билгеләренә тапшырдылар. С. М. Киров исмендәге 4 нче номерлы ясалма каучук заводы янындагы санитария дружинасы да яхшы эшли. Бу дружина составында күпчелек хатын-кызлар.

Шушы көннәрдә районда РОКК ның тагын 3 башлангыч оешмасы һәм берничә предприятиедә санитария постлары төзелде. Бәйрәмгә 100 кеше значкист булып хәзерләнеп чыкты.

## Чаңгы ярышлары

Шушы көннәрдә „Динамо" ның чаңгы станциясендә шәһәр беренчелеге өчен чаңгы ярышлары барды. Чаңгы ярышларының мондый массовый күләмдә бер вакытта да булганы юк иде әле. 28 спорт җәмгыятеннән 500 дән артык кеше катнашты.

Хатын-кызларның 5 километрга, ирләрнең 10 километрга хәрбиләштерелгән ярышлары аеруча кызыклы үтте.

Ярышлар группаларга бүленеп үткәрелде. „Медик" һәм „Динамо" җәмгыятьләренең ярышка нык хәзерләнгәнлекләре беленде. „Медик" командасы 1 нче группада беренче урынны, „Динамо"—икенче урынны алды. Икенче группада беренче урынга „Буревестник" җәмгыяте командасы, икенче урынга „Пищевик" командасы чыкты. ВУЗлар командалары арасында беренчелекне Мединститут командасы, икенче урынны Авиаинститут һәм өченче урынны Университет командалары алдылар.

Аерым чаңгычылардан Панкова („Наука"), Захарова, Харитонова һәм Тимофеев („Медик"), Шангина һәм Савощенко („Спартак"), Ганиева („Большевик"), Няшин („Крылья Советов"), Петров („Динамо"), Кречетников һәм Чукаева („Азот") иптәшләрне күрсәтеп үтәргә кирәк. Алар аерым дистанцияләрдә ярышларның иң яхшы нәтиҗәләрен күрсәтеп, алдынгы урыннарны алдылар.

*П. К.*

## Оборона значкистлары

Соңгы вакытта Киров районында оборона-масса эшләре шактый яхшырды. Хәзерге көндә районда 112 оборона түгәрәге эшли. Бу түгәрәкләрдә 2.400 кеше оборона белемен үзләштерәләр. Соңгы ике ай эчендә генә дә 970 кеше „Ворошиловча атучы" һәм „ПВХО" значокларына нормалар тапшырдылар.

Районның допризывниклары призыв көнен өчәр оборона значоклы булып каршылау турында йөкләмә алганнар иде. Хәзерге вакытта допризывниклардан 205 кеше „Ворошиловча атучы", 219 кеше „ПВХО" значокларына нормалар тапшырдылар. Допризывниклардан 90 кеше штык сугышын өйрәнделәр.

Йорт хозяйкалары да масса-оборона эшләренә актив катнашалар. Районның 10 йорт идарәсе янында Осоавиахимның башлангыч оешмалары төзелде. ПВХО инструкторлары хәзерләү курсында йорт хозяйкаларыннан 25 кеше укый. Мәктәпләрдә дә масса-оборона эшләре җәелә. Район мәктәпләре арасында үткәрелгән оборона ярышларында 66 команда катнашты. 10 нчы номерлы мәктәп укучысы Трутнев төз ату буенча иң яхшы күрсәткечне бирде. Ул мөмкин булган 50 очкодан 49 очко җыйды.

*Р. Бакиров.*



Я че часть командирларының хатыннары (Урта Азия хәрби округы) Ворошиловча атлылар түгәрәгендә занятиедә. Сулдан уңга—М. И. Орлова, А. К. Захарова һәм Е. И. Симякова иптәшләр.

Е. Халдей фотосы (ТАСС фотохроникасы).


11 нче март, кич 7 сәгаттә Шахмат-Шашка клубында (Матбугат йорты)

**Казан шәһәре шахматчыларының һәм шашкачыларының конференциясе чакрыла**

Көн тәртибе: Шәһәр Шахмат-Шашка секциясен яңадан сайлау һәм аның эш планы.

429—1

**КАЗГОРПРОМТОРГНЫҢ 12 нче МАГАЗИНЫНДА**

(Бауман һәм Куйбышев урамнары чаты, 9-88)

яңа алынган товарлардан

**һәр төрле тимер-калай һәм москатель-химик товарлар бар.**

Товарлар хәзер акчага гына сатыла. 428—1

**„ПРОМПОЛИГРАФ" АРТЕЛЕ**

**һәр төрле бланклар басу, китап төпләү, кәгаз тартмалар, пакетлар, конвертлар һәм хезмәт таныклыклары хәзерләү буенча — ЗАКАЗЛАР АЛА**

Казан Булакның уң ягы урамы, 35-2. 435—1

*Галиәсгар Камал исмендәге*

**Татар Дәүләт Академия театры**

Бүген, 8 нче мартта

**КЫЮ КЫЗЛАР**

Сезонлы урыннарга 131 нче талон белән кертелә.

12 нче мартта көндез 12 сәгаттә һәм кич

**БИШБҮЛӘК**

Талоннар: көндез 132, кич 133.

Спектакль кич 7 сәгат 30 минутта башлана. Касса һәр көн көндез 11 сәгаттән 2 гә һәм кич 5 сәгаттән 9 га кадәр ачык. ТДАТ.

**ТАТАР ДӘҮЛӘТ ОПЕРА ТЕАТРЫ**

Галиәсгар Камал исмендәге Татар Дәүләт Академия театры бинасында

Иртәгә, 9 нчы мартта

**ИРЕК**

Сезонлы урыннарга 84 нче талоннар белән кертелә.

Кич 7 сәгат 30 минутта башлана.

Коллектив рәвештә килү өчен 29—04 телефоны буенча заявкалар алына.

**ЗУР ДРАМА ТЕАТРЫ**

8 һәм 9 нчы мартта

**ЛЕНИН**

Талоннар: бүген 118, иртәгә 119.

Коллектив рәвештә килү өчен заявкалар алына. Спектакльләр кич 7 сәгат 30 минутта башлана. Билетлар көндез 11 сәгат 30 минуттан 2 гә һәм кич 5 сәгаттән 7 сәгат 30 минутка кадәр кассада сатыла.

**ДӘҮЛӘТ ЦИРКЫ**

Бүген, 8 нче мартта, данлыклы

**ЗОЛЛО ТИМЕР ЮЛЫ**

300 хайван һәм кошлар катнаша һәм башка күп номерлар.

РСФСР ның атказанган артисты һәм орденлы М. ЗОЛЛОның соңгы гастрольләренә билетлар сатыла.

Уен кич 8 дә башлана.

Касса һәр көн көндез 11 сәгаттән 3 кә һәм кич 5 тән 9 га кадәр ачык.

9 нчы мартта цирк эшләми. 9 ына алынган билетлар белән бүген керергә мөмкин.

**БҮГЕН КИНОЛАРДА**

| | |
|---|---|
| „ЭЛЕКТРО" 12, 2, 4, 6, 8 һәм 10 да. | Тавышлы, художестволы документаль яңа фильм СЕДОВЧЫЛАР |
| „УНИОН" 12, 2, 4, 6, 8 һәм 10 да. | ДУСЛАР |
| „КЫЗЫЛ ЙОЛДЫЗ" 6, 8 һәм 10 да | ЯШӘРГӘ |
| „ЧАТКЫ" 6, 8, 9-30 да. | БӘХЕТЛЕ ФИНИШ |
| „ПИОНЕР" 11, 1, 2, 4, 6, 8 һәм 10 да. | ДҮРТЕНЧЕ ПЕРИСКОП Көндез 1 сәгаттә мәктәпкә кадәр яштәге балалар өчен сеанс. |
| „Колхозник" 6, 8 һәм 10 да. | МИНИН ҺӘМ ПОЖАРСКИЙ |
| „РОТ-ФРОНТ" 6, 8, 10 да. | УКЫТУЧЫ |
| КУЛЬТУРА САРАЕ 5, 7, 9 да. | ПАТРИОТ |

**КИРӘК:**

„ГЛАВПАРФЮМЕР" нын ТАТАРСТАН КОНТОРАСЫНА (Лобачевский урамы, 3) БАШ БУХГАЛТЕР УРЫНБАСАРЫ.

350—3—3

Вахитов исмендәге Жиркомбинатка даими эшкә ӨЛКӘН РЕВИЗОР, ИНКАССАТОР, ИНЖЕНЕР-МЕХАНИКЛАР, ТЕХНИК-МЕХАНИКЛАР, ТЕХНИК-ИНСТРУКТОР-МЕХАНИК, ЧЕРТЕЖЧЫЛАР, МАШИНИСТКАЛАР, ИНЖЕНЕР-ЭЛЕКТРИК, ТЕХНИК-ЭЛЕКТРИК, САНТЕХНИКА БУЕНЧА ИНЖЕНЕР, 6—7 нче РАЗРЯД ТОКАРЬЛАР, ФИНАНС БҮЛЕГЕ НАЧАЛЬНИГЫ һәм ФИНАНС ЭШЛӘРЕН ЯХШЫ БЕЛҮЧЕ РЕВИЗОР. Тукай урамы, 152. Комбинатның кадрлар бүлегенә килергә.

426—2—1

Центроэлектромонтаж трестының Казан конторасына, Казанда һәм башка урыннарга китеп эшләү өчен, ирләрдән һәм хатын - кызлардан — БАРЛЫК РАЗРЯД ЭЛЕКТРОМОНТЕРЛАР, ЭЛЕКТРОСЛЕСАРЬЛАР, ПРОИЗВОДСТВОЧЫ БУХГАЛТЕР һәм берәр эш буенча квалификация алырга теләгән ГАДИ ЭШЧЕЛӘР. Кирәк кешеләргә тулай торакта урын бирелә. Контораның кадрлар бүлегенә килергә. Казан, Банк урамы, 13.

408—5—2

Казан 2 нче төзәтү-хезмәт колониясенә БУХГАЛТЕРЛАР, ӨЛКӘН БУХГАЛТЕРЛАР, КАРТОТЕКАЧЫЛАР, ХИСАПЧЫЛАР, ҖИТЕШТЕРҮ БҮЛЕГЕ РАБОТНИКЛАРЫ, ИНЖЕНЕР-ТЕХНОЛОГЛАР ҺӘМ АГАЧ МАТЕРИАЛЛАР СКЛАДЫ ӨЧЕН МӨДИР. Хезмәт хакы килешү буенча. Кызыл Армия бистәсе, 1 нче маршрут трамвайларының Петров паркы янындагы тукталы. Телефон № 19—22.

345—3—1


## Мастер—инициатор

Мастер булып күтәрелгәч берничә көннән соң, аның турында фабрика директоры хуҗалык работниклары киңәшмәсендә:

— Күпләрнең берсе һәм алдынгысы...— ди. Киңәшмәгә катнашучыларның барсы да директорның бу фикеренә кушылалар. Арадан кемдер фабрика техноругы Космасовка сорау бирә:

— Сез ничек уйлыйсыз, иптәш технорук?—ди. Технорук канәгатьләнгән. Өйрәнчектән мастер булу дәрәҗәсенә кадәр күтәрелгән стахановчы кызның бөтен эшен, осталыгын, омтылышын, үсү юлын белгәнгә күрә, аңа һәр вакыт якыннан торып булышлык күрсәткәнгә күрә, технорук аеруча канәгатьләнгән. Ул үзенә сорау бирүчегә күтәрелеп карый да:

— Эш уңышлы барыр, аның исме уңышлар белән бәйләнгән,—ди.

Бу 1940 нче елның башы иде. Шулай итеп ул, стахановчы кыз Язилә, яңа елны яңалык белән—мастер булу белән каршылый.

Аны бу эшкә күтәрү белән бер кем дә ялгышмады. Уңышлар берсе артыннан берсе килә башлыйлар. Аларның барсын да техниканы белгән, машиналарны җентекләп өйрәнгән, технология процессларын тырышып үзләштергән кешеләр хәл итәләр.

Яш мастер беренче көннән үк кешеләргә якын килә белә, аларны эштә өйрәнә, аларга үз тәҗрибәсен күчерә белә. Кешеләргә ул уңыш теле һәм аларны үзенә ияртә белә. Бу сыйфатны ул тәҗрибәле, квалификацияле, үз бурычын тулы үтәүче работниклардан ала. Алдынгыларның эше аны һәр вакыт бик нык дәртләндерә. Кем яхшы эшли, ул аңа сокланып, кызыгып карый. Ул бригада членнарына бик еш:

— Сез үрнәк алудан бер дә курыкмагыз. Алдынгы кешеләр бик күп. Алар шикелле итеп эшләргә кирәк,—дип сөйли.

Ә үзе шул минутта ук көндәлек эшкә күмелә, кешеләргә җентекләп карый, аларның бөтен сорауларын үти.

Кайчан гына карасаң да мастер эшчеләр, машиналар, товарлар янында була. Ул барсын да тикшерә, учет эшләренең дөрес алып барылуы белән, хезмәт дисциплинасы кагыйдәләренең тулы үтәлүе белән һәм башка шундый бик күп мәсьәләләр белән әледән-әле кызыксынып тора. Мастер үз участкысыннан каядыр китеп йөрергә, производстводан аз гына вакыт булса да аерылып торырга теләми. Ул һәр минутның кадерен белә, вакытны юкка әрәм итмәү өчен бөтен чараларны күрә.

Яш мастер җитәкчелегендә эшләүчеләрнең барсы да кызлар. Аларның барсы да диярлек Бөек Социалистик Октябрь революциясе елларында һәм аннан соңгы елларда туып үскән кызлар. Аларның һәр кайсы орденлы Татарстан республикасының данлыклы XX еллык бәйрәменә үзенең кадерле бүләген хәзерли. Бүләк хәзерләү теләге белән алар, зур комбинатның бөтен коллективы белән бергә, республикабызның эшчеләрен, эшче хатын-кызларын, барлык хезмәт ияләрен социалистик ярышка чакырдылар. Бу инициатива завод, фабрикаларга, колхозларга, совхозларга, учреждениеләргә, уку йортларына яшен тизлеге белән тарала. Ул—яш мастер җитәкчелек итә торган участкы һәм бөтен мех комбинат коллективы чакыруы буенча башланган ярыш—хезмәт ияләрен яңа көрәшкә, яңа җиңүләргә дәртләндерә.

Бу инициативаны башлап йөргәндә Язилә бригада членнарының бер киңәшмәсендә:

— Бөтен республика күләмендә сүз барганда безнең бурычыбызның һичаклы зур булуы сезгә билгеле, иптәшләр. Без бөтен эштә алдынгы булырга тиешбез. Миң ышанам, безнең кызлар үзләрен сынатмаслар!— дип чыгыш ясаган иде.

Моннан соң шактый көннәр үтте инде. Ә бригада членнары бер туктаусыз алга баралар, ярыш байрагын югары күтәрәләр.

Участкыдагы һәрбер эшче үзара ярыша. Ярышның нәтиҗәсе бик яхшы күренә. Менә күпләрнең икесе: Зәйтүнә Заһитова һәм Бәнат Гайнетдинова иптәшләр. Алар үзара ярышып эшлиләр. Зәйтүнә норманы 350—400 процент итеп үти. Ай саен 700—800 сум хезмәт хакы ала. Бәнат аңардан калышмый. Норманы шул ук күләмдә үти. Бер үк күләмдә хезмәт хакы ала. Ә мастер аларга шартлар тудыра, булыша һәм ярышучы иптәшләрнең һәр төрле сорауларына вактында колак сала. Шуның белән бергә, ярышучылар һәр кайсы бер-берсенә булыша, иптәшенә уңыш теле һәм шуны эш белән күрсәтә. Ярышучы ике иптәш смена тәгәлләнгәннән соң үзара сөйләшәләр, бүген күпме эшләүләре турында сорашалар. Шул вакыт мастер бик тиз генә алар янына килеп җитә, теге яисә бу кимчелекләрнең булуын ишетсә, икенче көнне җитешсезлекләрнең кабатланмавына ирешә.

Ярыш әнә шулай башланды һәм шулай дәвам итә. Участкыда үзләренең нормаларын икешәр-өчәр тапкыр һәм аннан да арттырып үтәүчеләр саны арта бара. Мона ирешү өчен, иң беренче чиратта, мастерга аеруча тырышлык күрсәтергә туры килде. Менә бригада члены Шура Дудорова. Ул 4 нче мех фабрикасының кисү цехына—Язилә җитәкчелек итә торган участкыга өйрәнчек булып килә. Ул тәрбиячесез калган кыз. Аның характерында кире яклар очрый. Язилә бу яш кыздагы кимчелекләрне бетерү өчен аны үз контроле астына ала. Шуннан соң Дудорова производствоны ярата башлый. Комсомол сафына керә. Ә хәзер ул алдынгылар сафына басты. Норманы системалы рәвештә 200 процент итеп үти.

Фабрикага күптән түгел өйрәнчек булып килгән Сания Әхмәтҗанова, Мәрфуга Камалеттинова һәм башка иптәшләр хәзер алдынгы эшчеләр—стахановчылар булып әверелделәр. Разия Шәмсиева һәм Әминә Шадрина иптәшләр аз вакыт эчендә ударник булдылар. Мастерның игтибары хәзер аларны да стахановчылар итүгә юнәлдерелгән. Моңа ул тиздән ирешер. Ә Мәдинә иптәш Шәйхуллина шушы көннәрдә генә эшли башлады. Бу яңалык аның тормышында әле беренче тапкыр. Шуңа күрә дә мастер аның янында тагын да күбрәк була.

... Хезмәт ияләре депутатларының җирле Советларына сайлаулар алды иде. Зур һәм якты залда җыелыш бара. Цех начальнигы иптәш Емельянов сүз ала, Сталин район Советына депутатлыкка кандидат итеп мастер Язилә иптәш Гатауллинаны күрсәтә. Җыелышка катнашучылар Язилә кандидатурасын лаеклы дип табалар. Сайлаулар көнендә хезмәт ияләре үзләренең тавышларын бердәм рәвештә аңа бирәләр.

Ул, депутат буларак, хәзер җәмагать эшләренә тагын да зуррак энергия белән керешә. Ул сәүдә комиссиясендә эшли. Сәүдә мәсьәләсе бик җидди эшләрнең берсе. Аны тагын да тизрәк үстерергә, бу тармактагы кимчелекләрне ашыгыч бетерергә кирәк. Язилә һәм башка иптәшләрнең фикере әнә шундый.

*Г. Сәет.*

## Шәһәрне киңәйтү

Куйбышев гидроузелы төзелеше уңае белән Казан шәһәрен киңәйтү мәсьәләсе алга куелды. Ленин районында һәм Горки авылы тирәсендә торак йортлары салу өчен яңа җир участкылары билгеләнде.

Хезмәт ияләре депутатларының Казан Шәһәр Советы Башкарма Комитеты шәһәрне көнчыгыш юнәлешенә таба да киңәйтүне кирәкле тапты. Ершов кырында яңа йортлар, гараж һәм халыкның сәламәтлегенә зарар китерми торган предприятиеләр төзеләчәк. Шәһәрне киңәйтү өчен Малые Клыки авылындагы „Память Ленина" колхозы 135 гектар җир участкысы бирә. Бу колхозның үзенә калган 527 гектар җиреннән яхшырак файдалану чаралары күрелә. Анда яшелчә культуралары чәчү мәйданы киңәйтеләчәк һәм парник хуҗалыгы оештырылачак.

## Яңа коелар

Сталин районына кергән Поповка, Кукушкино, Калинин, Воскресенская поселкыларында торучы эшчеләрне су белән тәэмин итүне яхшырту теләге белән, быел 6 урында кое казу планлаштырылды.

Эшчеләр поселкыларында кое казу эшләренә 18 мең сум акча җибәрелде.


Җаваплы редактор
һ. АБДРАХМАНОВ.
Ответ. редактор Х. АБДРАХМАНОВ.